ӘКЪЛИМӘ САЯПОВА

# ЙӨРӘК СЕРЕ

*Шиғырҙар һәм поэмалар*

ӘКЪЛИМӘ САЯПОВА

# ЙӨРӘК СЕРЕ

*Шигырьләр һәм поэмалар*

ШКОЛА

Казань
2008

УДК 820/89 (470).0
ББК 84/2Рос=Тат)-6
С 22

**Саяпова Ә.**
**С 22** Йөрек сере: шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: РИЦ «Школа», 2008. – 176 б.

© Саяпова Ә.Ш., 2008
© Оформление РИЦ «Школа», 2008

## «ҖЫРЫМ БУЛДЫ ЮЛДАШ ОЗЫН ЮЛДА...»

Укучыларга тәкъдим ителгән шигырьләрнең һәм поэмаларның авторы – минем әнием – гаҗәеп кеше иде. Аның язмышы күп яклары белән үзенең замандашлары язмышына охшаган. Бик күп россиялеләр өчен уртак булган сугыш, сугыштан соңгы тормыш авырлыклары аның шигырьләрендә чагылыш табып кына калмыйча, тормышны үзенчәлекле бәяләү тосләрен дә билгеләи: Бөек Ватан сугышында катнашкан кеше буларак, ул үз тормышына да, һәм гомумән тормышның күп якларына сугыш дәһшәтләрен, тылдагы михнәтләрне, сугыштан соңгы чорның авырлыкларын кичергән кеше буларак карый. Мондый караш, әлбәттә, аның холкын беләүләгән, төп ориентирларны чарлаган. Фашистлар белән сугышны башыннан ахырына кадәр үтеп, аның афәтләрен беренче көннәреннән алып Европаны азат иткәнгә кадәр кичергән әткәем кебек үк (ул сугышта политрук, сугыштан соң – партия райкомы хезмәткәре, аннан – район газеты хезмәткәре), әнкәем дә – инанган коммунист. Алар коммунизм идеяләрен гуманизм, әхлаклылык, сайлаган тормыш юлына тугрылык, илгә намуслы хезмәт итү мәгънәсендә аңлаганнар һәм кабул иткәннәр.

Әклимә Саяпова тормышындагы төп эше укытучылык, ул гомере буе Яңавылның 1 нче номерлы мәктәбндә (Башкортостан)татар теле һәм әдәбияты укытты. Ул эшләгән чорда әлеге мәктәп үзенең бай традицияләре белән бөтен республикага танылды, аның укыту-методик тәҗрибәсе төрле басмаларда чагылыш тапты. Бүген бәлки күпләргә аңлашылып та бетмәс, әти белән әни «балык тирәнрәк, кеше яхшырак җирне эзли» дигән принцип белән яшәмәделәр. Алар гомер буе үзләренең принципларына һәм идеалларына тугры калып, гадел яшәп һәм эшләп, намуслы тормыш кичерделәр. Әлбәттә, аларның тормышлары җиңел булмады. Алар буы-

ны билгеле бер дәрәҗәдә романтиклар – Донкихотлар буыны булды: фашизмны җиңгән ил булдыклы ил һәм аның кешеләре дә яхшырак тормышта яшәргә лаеклы (әтием сүзләре) кебек тоела иде аларга. Дөрес, әти дә, әни дә гомерләренең соңгы елларында тормыштан, заманадан һәркайсы үзенчә канәгатьсезлек кичереп яшәде, чөнки ул тормыш аларның идеалларына, карашларына-мәсләкләренә туры килми иде. Бәлки мондый күренеш аерым заман өчен генә түгел, гомумән, табигый эволюция кичергән кешелек тормышы өчен хас нәрсәдер: һәр буын үз тормыш тәҗрибәсе аша үтеп, үз идеалларын дөресләү-турылау, аны шик астына алу мәҗбүриятенә киләдер.

Сәнгатькә, шигъри сүзгә тартылу әнкәемнең табигатенә хас, нәселдән килә торган сыйфаты: әнкәйнең әтисе – минем бабам – бәетләр чыгара торган булган, энесе Рафаэль Галиев исә – Башкортстанның атказанган артисты, сәнгатьле сүз, сәхнә остасы.

Әнием гомере буе (мин аны күпме беләм, шулхәтле) шигырьләр язды. Хәтерлим, әле мин бала чакта китапханәсе дә, китап кибете дә булмаган бәләкәй бер Айбүләк авылында яшәгәндә әни безгә, кызларына, балалар өчен шигырьләрне үзе яза иде. Мин ул шигырьләрне бүген дә яттан яхшы хәтерлим. Соңыннан шигырьләрне ул үз укучылары өчен, алар белән бергәләп яза башлады. Үзе шигырь яза белмәгән һәм укучыларын шигырь язарга өйрәтә алмый торган ана теле укытучысы булу турындагы уй аның башына да килми иде.

Шагыйрь язмышы җиңел булмый, һәм шулук вакытта язмыш үзе кешене шагыйрь итә, аның шигъри сүзенең табигатен, үзенчәлеген билгели. Тормышы, дуслары, коллегалары, үзенең укучылары, гомумән, үз тормышындагы кешеләр турында язды әни. Аның иҗаты – тормыш көндәлеге, күңел көндәлеге. Тормышны ул күңеле белән шатланып та, тетрәнеп тә, ә кайвакыт әрнеп-сызланып, көенеп тә кабул итте.

Яшәүгә омтылышының нык булуы, тормыш каршылыкларына бирешмәү аның иҗатын кабындырып, дөрләтеп торды. Әлеге омтылышта – тормышның шатлыгын да, фаҗигасен дә аңлау, кеше үзе үзгәртә алмаган, тәкъдир белән билгеләнгән котылгысызлыкны аңлау да бар. Кешенең соңгы сулышына кадәр, актык көче калганчы әнә шул ашкыну яшәтә ...(«...Мин арыдым. Тиздән туктап калам..» дигән шигырь юллары искә төшә). Яшәү омтылышы тормышны мәңгелек хәрәкәттәге чиксезлек буларак кабул итәргә һәм шул ук вакытта үз гомереңнең чикләнгән булуын аңларга ярдәм итә һәм шигырь юлларына оптимистик төсмер китереп кертә:

Йөкне ал да, юлны дәвам ит...
(«Укытучы булган укучыма»)

«Йөрәк» дип исемләнгән җыентыктагы беренче шигырьдә (автор аны үзе туплаган һәм төзегән) шагыйрь күңеленә тынгылык бирми торган, ашкынучан, каршылыклы, бәргәләнүче йөрәге турында сүз бара:

Йөрәк, йөрәк!
Җанга тынгы бирми,
Эзләнә дә һаман эзләнә.
Кайчагында күккә үрелә дә,
Табигатьтән сорап тезләнә.
Эссе чакта куе болыт эзли,
Яңгыр ява – эссе нур эзли.

«Йөрәк-җан» парлы образы аша кешенең җисми һәм рухи барлыгының берләшүе-ярашуы аңлашыла. Җир, дөнья мәшәкатьләреннән янып торган тынгысыз йөрәк рухилык сыйфатын да билгели сыман... Шагыйрь йөрәге бөекне, рухилыкны җир, кешелек белән тоташтыручы үткәргеч ул. Шул рухи-

лык йөрәккә көч биреп, аны канатландырып тора, тормыш дәһшәтләреннән саклый.

Табигать шагыйрь өчен матурлык һәм илһам чыганагы гына түгел, ул тормыш фәлсәфәсе чыганагы да. Мәсәлән, «Яфраклар» дигән шигырь түбәндәге юллар белән башлана:

Яфракларның гомеркәе бары бер җәй,
Җиргә ява сары яфрак, кызыл яфрак.
Җәй көнендә яшел булып яшәде дә,
Көз көнендә ята җирдә, булыр туфрак.

«Булыр туфрак...» – бу сүзләрдә яшәешнең мәгънәсе, аның мәңгелек асылы чагыла. Бернәрсә дә эссез югалмый, яшәеш чыгырында һәрнәрсәнең үз вакыты бар. Бу сүзләрдә яшәешнең мәңгелек сере дә яшеренгән... Шуны аңлау – кешелек яшәешенең чикле булуын аңлау, һәм бу шигырьнең сагыш, әрнү хисләре белән сугарылган юлларын хасил итә:

Мәңгелеккә аерылу авыр шул ул..

Ләкин шунысы гаҗәп, шигырьнең алдагы «Гомерлеккә сагыш кала, бирсен, түзәм» дигән юлларында кеше рухының көче чагыла. Шул көч өметсезлеккә бирелмичә, тормышны акыл белән кабул итәргә ярдәм итә. Әлеге мәгънәдә табигать үзе укытучы, бәлки, кешенең җирдәге гамәлләренең үлчәве булып аңлашыла:

Тик бер бөртек яшел яфрак кадәр генә
Файдам тисә туган җирем – кадерлемә,
Кирәк түгел бушка үткән озын гомер...

«Җырлыйсы бар» шигыре физик һәм рухи талчыгу кичерүдән соң язылган. Инде көч тә беткән, тормыш, яшәү өчен

көрәшүнең дә мәгънәсе калмаган, үлем сәгате якынлашу белән ризалашыр халәт килгән, әмма үлем әлегә чигенә... Чөнки шагыйрь җаны җирне яз көне калдырып китә алмый:

Җырчы җанның язда киткәне аз.

Ә көзен

Көзге җилләр әле яфракталар,
Чәчәкләрен сөеп җырлыйсым бар...

Үлем әнкәемне тормыштан көзен алып китте. Язда ул утырткан һәм үстергән чәчәкләр, көзен аны шигырьләр язарга рухландырырга тиешле чәчәкләр, аның кабере әстенә кызыл бәрхет булып яттылар.

Җыр белән яши белү («Җырым булды юлдаш озын юлда...»), тормышыңны җырга әйләндерә алу, дөньяны, тормышны җырларың аша күрә белү кеше язмышының авыр вакытларында тормыш кыенлыкларына, каршылыкларына бирешми яшәргә ярдәм итә, яшәеш көче бирә. Җыр белән яши белү тормыш прозасын шигырьгә әйләндерә, тормыш прозасы эчендә үзеңнең тормыш фәлсәфәңне табарга өйрәтә:

Яшәү сукмагымны ярам,
Бураннар күмгән саен.
Бәхет көтәм...

Альбина Саяпова,
филология фәннәре докторы профессор.

## ЙӨРӘК, ЙӨРӘК!

Җанга тынгы бирми,
Эзләнә дә, һаман эзләнә.
Кайчагында күккә үрелә дә,
Табигатьтән сорап тезләнә.
Эссе чакта куе болыт эзли,
Яңгыр ява – эссе нур эзли.
Әнә тарих...
Тарих артка шуа,
Туктатырга көчле кул эзли.
Чамалыдыр көче йөрәгемнең,
Тик... канатлы бит ул. Канатлы!
Каергалап аның канаткаен,
Явыз җаннар ничә канатты!
Терелә ул.
Бик тә чыдам йөрәк.
Кечкенә дә, үзе төш кенә.
Ут кабынгач, дөнья сакалына,
Кунды очып...
Димәк, көч кенә!
Көйсез заман.
Гаделсезлек һаман
Көйдергәли канат очларын...
Ярый әле, энҗе-мәрҗән эзләп,
Йөрәккәем,
Ташлап очмадың.

## ИКМӘК

Барам йортлар арасыннан
Ерак түгел шоссе юлдан.
Күзем төште кисмәкләргә
Төрле чүпләр белән тулган.
Исем китеп, туктап калдым,
Икмәк ята чүп өстендә.
Кимергәннәр, таптаганнар,
Кош-корт эзләре өстендә.
Борынгылар киртәләгән
Бөртек иген төшкән җирне.
Сүтмәгән киртәне һичкем,
Аңлаганнар изге серне.
Изге икмәк чүпкә чыккан,
Кем ташлаган? Ник ташлаган?
Кайсы гамьсез, масаеп,
Икмәктән уза башлаган?!
Яшәү биргән зур көч – икмәк!
Тик көрәштә туган икмәк!
Икмәк...
Икмәк, әнә, чүпкә киткән.
Изге икмәк хәрәм булсын
Әрәм итеп яшәүчегә.
Әй, кешеләр!
Узмыйк әле,
Хөкем кирәк ташлаучыга.

## ҖЫРЫ КАЛДЫ КҮҢЕЛДӘ

(баллада)

Кызларны  сугышка алдылар,
Юл тулып, озатып бардылар
Танышлар, кардәшләр, туганнар,
Әнкәйләр кайгыда калдылар.
Болында чайкалды чәчкәләр,
Хушлашып, хуш исләр сиптеләр;
Актылар түбәдә болытлар,
Алар да яшьләрен түктеләр.

Көнбатыш ягына юнәлде
Кызларны төягән вагоннар.
Юл буе җырлыйлар татарча,
Бар хисләр моң булып агалар.
Менә без Мәскәүдә. Тукталыш.
Һаман җыр... Зөбәрҗәт моңая.
Читтәрәк карт солдат җыр тыңлый.
Тыңлый да, сокланып елмая.
Җыр ага... Карт солдат килде дә,
Вагонга терәде маңгаен.
Сөйде ул, яратты вагонны,
Күзенә яшь тулды мөлдерәп.
– Рәхмәт, вагоным, мең тапкыр, – ди, –
Китердең туган як җырларын.
Исән  кайт, моңлы кыз, чибәркәй!
Куанып тыңласын үз ярың...

Сугышта бар булган кызлар да
Җәй – янды, кыш –  туңды, арыды.
Хезмәт тә,  әҗәл дә бер төрле,
Ир солдат язмышы бары да.

Шулай да бәхетле көн җитте.
Шатлыкка әйләнде газаплар.
Ул җиңү китерде дөньяга,
Сугышны үлемгә озатты.
Ал таңнар тудылар... Тын көннәр...
Зөбәрҗәт аларны күрмәде.
Җиңүгә ике көн калганда,
Җырчыны урманда җирләдек...

Солдатлар кайталар, кайталар!..
Урманнар йөгерә каршыга.
– Моңлы кыз Зөбәрҗәт кая? – дип
Сорыйлар чәчкәләр барысы да.
– Саклагыз күңелдә, сагынып,
Зөбәрҗәт сугышта калды, – дим. –
Ул сакта торганда, аттылар,
Мәңгелек йокыга талды, – дим.
Зөбәрҗәт җырлары күңелдә
Хәтердән югалмас моң иде.
Көрәшнең ул үткән сукмагы
Бәхеткә китергән юл иде.

## ЧЫРШЫКАЕМ

Чыршыкаем, купшыкаем,
Йоп-йомшак энәләрең.
Энәләреңне нурласын,
Йолдызлар әләм әле.
Бәйрәм күлмәге кигәнсең,
Нинди горур сынкаең!
Үскән җирдән аерылып
Килгәнсең, сылукаем.
Яңа ел килә, Яңа ел!
Чыршыдай булсын чыдам,
Чыршылар көлеп карыйлар
Корыда сусаучыдан.
Яшел чыршы бизәп куйдык
Яңа ел юлларына.
Шатлык өмет итеп көтәм,
Шәм тотып кулларыма.

## ТОРМЫШНЫ МИН ГЕЛ ҮЗЕМЧӘ АҢЛЫЙМ

Бәхәс бара. Әйтеп куя берәү:
– Мондый явыз каян табылсын.
– Җан көйдергеч явызлык булмаса,
Яхшылыкны ничек танырсың?
– Иң авыры – хыянәт, – ди берсе,
Җирдә хыянәтче булмасын.
– Хыянәтсез яшәү матурлыгын
Каян сизеп, ничек аңларсың?
– Гомер юлы җиңеләер кебек,
Сугыш киртә булып тормаса.
– Тынычлыкның хакы кимер кебек,
Әгәр Җирдә сугыш булмаса.
Үзгәрергә кирәк, үзгәрергә...
Сүзләремнән мин дә чигенәм.
Бүген бездә фикер буталышы.
Килеп җиттем, бугай, чигенә.
Бәхет базарына илтә торган
Тыныч тормыш бирсен яшьләргә.
Ризамын, һич тә бәхәсләшмим,
Олы гамьсез булып яшәргә.

## ГОМЕРЛЕК ЯРАТУ

*Яңавыл районының*
*«Победа» колхозы рәисе*
*Мәсгут Кашаповка багышлыйм*

Болыннарны буйлап балачакта,
Кошлар көен тыңлап үскәнгә,
Кеше карый икән бүген итеп,
Еракларда калган үткәнгә.
Туган ягын үз дөньясы итеп,
Тану туа икән канында.
Утта янмый, суда сүнми торган
Сөю шулдыр кеше җанында.
Үсеп җитеп килгән уңган егет
Иген игә, туган җирендә.
Җитә вакыт, күңел, канатланып,
Оча хыял кошлар иленә.
Дөнья ямьле,
Хисләр шашыналар...
Эшләп туймый,
Арта бара көч,
Үсеп кенә килгән бер чибәрнең
Яратуын сизеп калган ич.
Тик кулыннан тотып карарга да
Кыенсынды егет, кыймады.
Очрашканда, нурлы йөзле кызны
Егет һаман күреп туймады.
Ярата ул керфек сирпүләрен,
Көлеп торган моңсу күзләрен.
Ярата ул кызның бик ягымлы,
Йөрәгенә җылы сүзләрен.
Елмая кыз – мәхәббәте моңы,

Сөюенең тәүге ал таңы.
Сөйгәнеңнең елмаюыннан да
Кадерлерәк нәрсә бар тагы?!
Аяз көнне яшен суктымыни,
Аяк баскан җирләр селкенде,
Кояшның да йөзе моңсуланды,
Ай, йолдызлар елый шикелле.
Афәт килде җиргә, көтмәгәндә,
Фашист ябырылды илемә.
Илне саклау өчен йөк төялә
Яшь егетнең яп-яшь иңенә.
Кинәт олгайды ул. Яшьлек шиңде,
Сулды яшьлек, чәчкә атмады.
Патронташ тагып, мылтык асып
Сугыш сукмагыннан атлады.
Үтте еллар, үтте ничә айлар!
Һәр минутның күпме газабы?!
Интегүләргә дә түзәр солдат,
Бәхет китерерме азагы!
О, ул сугыш! Ох, ул канлы сугыш!
Күпме гомер – яңа роман,
Күпме яшьлек – тормыш матурлыгы
Ятып кала, кабат торалмый.
Ә ул торды. Басты безнең Мәсгут.
Авыр яра алды ике кат.
Ата-ана догасымы алган
Җәллад балтасыннан аралап.
Уйлар, хыялларга вакыт була
Госпитальдә яра тынганда.
Роза чәчәгедәй сөйгән яры
Күңелендә була, гел янда.
Күз алдында ята дулкынланып,
Зур башаклы бодай кырлары.

Җилләр уйный арыш басуында,
Күңелендә башак җырлары.
Яу кырына тынлык, тынлык кайтты...
Сүнде сугыш дигән зур учак.
Күмелгәннән килә кайгы йөге,
Тере калган гомер итәчәк.
Гомер юлы... нинди сикәлтәле!
Ниләр көтә алда, кем белә!
Илдә – ачлык. Тәндә – авыр яра.
Яшәү – хәерчелек гел генә.
Егет туган авыл хәлсезләнгән,
Көләч яшьлек тә иртә үткән.
Күңелендә гел елмаеп торган
Чибәркәе тормышка киткән.
Юк, балтасы суга төшми аның.
Күңел каткан, күреп югалту.
Ата-бабалардан калган чара -
Җанны хезмәт белән юату.
Менә яшьтән урак урган басу...
Чүп үләне белән капланган.
Җир җылысы, аның изгелеге
Егет күңелендә сакланган.
Хатын-кызлар көрәк белән ертып,
Сыер җигеп сөргән ел иде.
Кара кайгы, канлы яшьләр белән
Сугарылган туган җир иде.
Исән калган бик аз ирләр кайта,
Көч кимегән, тапсын кайлардан?..
Эшчән егет шундый көйсез елда
Председатель итеп сайланган.
Илле икенче ел. Колхозчының
Кеше нуры беткән йөзендә,
Бер стакан онга хезмәт итә

Көн буена басу өстендә.
Эшләр өчен шартлар: арык ир-ат,
Ачыгудан тузган газиз җир.
Шуннан башлап, күпме хезмәт сала,
Күпме акыл... Күпме түккән тир!
Егет күңелендәге асыл таш:
Кешеләрне, җирне ярату.
Бишектәге бала кебек көйләп,
Җир тук булсын өчен җан ату.
Ничә еллар шулай янып яши.
Сокланалар аның эшенә.
Бәхетлеме? Тулы бәхет өчен
Җан азыгы өстә кешегә.

Я, Ходаем! Бар бит изге эшләр!
Игезәкләр туа дөньяга.
Инде үсә. Үсә ике кызы.
Елмайгандай аңа Җир-ана.
Хәзер инде алар житеп килә,
Бигрәк охшаш икән үзләре.
Шундый, шундый гүзәл Нәфисәсе!
Искитәрлек нәфис Гүзәле!
Күзләрендә – йолдыз, кашлар – кыйгач,
Йөзләрендә уйный таң нуры.
Энҗе чыңлавыдай сүзкәйләре,
Күңелләре тулы кыз моңы.
Нинди корал тотса, шунда уйнап,
Уяталар йөрәк кылларын.
Моңлы шатлык белән бизи алар
Әтисенең гомер юлларын.

Сүзләр йөри һаман аның хакта:
– Эшләп арыганын күрмәссең.
Кулыннан да килә, теленнән дә,

Җиденче дистәдә, димәссең.
– Яшь хатыннан йога, имеш, яшьлек...
Картлык тими эш сөйгәннәргә.
Яныл-пешеп, берсен бишкә бүлеп,
Дөнья куып йөргәннәргә.
Хезмәт дәрте аның йөрәгендә.
Жирне яратуы – гомерлек.
Җирне сөйгән – көчне жирдән алган,
Күктән эзләп йөрми тилмереп.
Быел килә кырык бишенче кыш.
Ул үстергән иген кырына.
Кар юрганын яба, калынайта,
Өрмәсен җил «балаларына».
Фән китабы тотып, азык эзли,
Бер бөртеге ачлык күрмәсен.
Җиргә тирен түккән кешеләре
Читтән бәхет эзләп йөрмәсен.
Үзгәрешләр чоры. Авыр заман.
Хаклар, хаклар! Ничек үстеләр!
Бөтен өметләрне, хыялларны
Үтмәс пычак белән кистеләр.
Аның өметләре киселмәгән.
Нинди кеше – Алла бәндәсе!
Бу заманның ачы җилләреннән
Саклый, ахры, акыл пәрдәсе.
Әнә бит ул... һич ни булмагандай,
Атлый бирә үзе юлыннан.
Авызлыклап, кысып тота чорны,
Үзгәртә ул... Килә кулыннан,
Заман батырында - фантастик көч.
Сорап тормыйм каян килүен.
Ишеткән бар: «Җирне чынлап ярат,
Хезмәтне кызганма», – диюен.

Беркен шулай, инде шәфәкъ баткач,
Ике үсмер кага капкасын.
Тиз-тиз атлап чыга хуҗа кеше,
Ярмасын, дип, капка тактасын.
– Колхоз бабай! Алма өзик әле,
Бераз гына синең бакчаңнан?
– Бүгенгә өз. Аннан базарга бар,
Өлеш чыгар бераз акчаңнан.
Бер тиен дә акча сорамый Җир.
Утырт, энем,  үзең алмагач.
Гомер буе хәер сорарсың бит,
Үз бакчаңда алма булмагач.
Ай Кояштан нурлар алган кебек,
Көчне ала Мәсгут гел җирдән.
Бәхете дә, байлыгы да җирдән,
Өзелмәстәй өмет тә Җирдә.

## ДӨНЬЯ ҺАМАН ЕЛЫЙ

Нинди генә булыр бу яңа ел.
Шатлыклары белән килерме?
Туксан тугыз куйган авырлыктан
Чыгу юлкайларын белерме?
Акыл ияләрен алып калды,
Эзе калды тарих битендә.
Әнгам калды, Нажар Нәҗми калды,
Фатыйма апа калды бит инде...
Дөнья һаман көя алар өчен,
Дөнья елый, дөнья кайгыра.
Яңа елга карап елмая ул,
Башын ими, имеш, кайгыга.
Гәүдәләрен алды җир кочагы,
Җыркайлары һаман очалар.
Күңелләрдә йөри сүзкәйләре,
Бар дөньяны үбеп кочалар.
Бу кайгыдан чыгу юлын тапмас,
Яңа ел табардай эш түгел.
Башка борчулар да баштан ашкан,
Аларын көйләсә, хуш күңел.

## УЗГАН ЧАКТА

Шык-шык итеп, чик-чик итеп,
Таш тия тәрәзәмә.
«Ватасыз бит тәрәзәне,
Кем тия соң мазама».
Баскан да, елмаеп тора
Бер егеткәй каршымда.
«Атна эзләп, чак таптым», – ди,
Тик сөю карашында.
«Очраттым мин сине юлда,
Ошадың күңелемә.
Борылып артыңнан килдем...
Ярым бул гомеремә?»
«Ярым да бар, бар балам да,
Кирәк түгел син миңа.
Юлда әйбәтләр күп булыр,
Пар булмый бит ул сиңа».
Инде менә ничә еллар
Егет эшеннән кайта.
Таш атмаса да, һаман да
Узган чакта күз ата

## ЙӨРӘГЕМДӘ УЧАК ЯКТЫМ МИН

Синең сөю шундый кайнар кайчак –
Йөрәгемне саклыйм пешүдән,
Ә кайчакта боздай салкын була,
Күңел гөлем корый өшүдән.
Беләм инде: янып сөяр өчен,
Кояш бүләк иткән ялкынын.
Уйландырды, каян аласың, дип,
Күңел ишетерлек салкынны.
Сөю, сөю!
Мәңгегә яшь, зур хис!
Сүндермәскә чара таптым мин.
Җәйләр үтеп, көзләр якынлашкач,
Бу хикмәтнең серен ачтым мин.
Синең күңел суынмасын өчен,
Йөрәгемдә учак яктым мин.
Янып сөйгән чакның ялкыннарын
Шул учакта тотып саклыйм мин.

## КҮҢЕЛЛӘРНЕҢ АЛТЫН КОЯШЫ

Әй, яңарыш! Алмаштырыйкмы әллә
«Сөям» һәм «яратам» сүзләрен?
Кечкенәләр, ахры, сыйдырмыйлар
Безнең заман йөрәк хисләрен.
Сөю бит ул якты, олы, гали,
Үтә нечкә, чиксез моңлылар.
Нигә ярсу, дисез, егетләрне?!
Сөю хисе белән тулылар.
Мәхәббәттән шашкан йөрәкләрдә
Шатлык, сагыш, кайгы бар сыман;
Ул йөрәктә тылсымлы көч, дәрт бар,
«Сөям» сүзе моңа тар сыман.
Хисләр, хисләр! Их, сез, җылы хисләр –
Күңелләрнең алтын кояшы.
Хәер, нигә сүзләр?.. Гашыйк күздә
Очкын чәчә бриллиант ташы.

## КАВКАЗ

Ташлый язмыш уйлар диңгезенә,
Бата-калка һаман йөзәм мин.
Авыр кайгы йөген күтәргәнмен,
Белмим, ничек кенә түзәм мин.
Черек державаның явыз башы
Халык күңеленә күз салмый.
Дан эзли ул корбаннар саныннан,
Үткәннәргә карап юл сайлый.
Чал сакаллы Кавказ әле горур,
Күз яшьләре тама... Бөгелми.
Кан каплаган яралы йөрәген.
Таш шул Кавказ. Таш ул егылмый.
Башны ташка бәреп яручылар
Таш итәктә ятып калалар.
Кычкырасым килә: «Нишлисез Сез?
Таш ватылмас, юньсез балалар!»
Заман башка. Хәзер батырлыкны
Акыл көче белән яуларга...
Сезгә, корал тоткан Ватандашлар,
Башың исән чакта уйларга...
Кодрәтлеләр, әмер бирүчеләр!
Бер үк көнне, бер үк сәгатьтә
Ташлатыгыз коралларны кулдан!
Һәм тынычлык кайтыр шул чакта.

## СУГЫШ КАЛДЫ МИНЕМ ЙӨРӘКТӘ

Олы бәйрәм.
Кара кайгы катыш.
Аны ничек акка буярга?
Күңел бәйрәм белән тулсын өчен
Кайгы йөген кая куярга?
Әллә тилеримме хәмер эчеп,
Акыл йозагыннан ычкыныйм..
Уралтауның түбәсенә басып:
«Без – җиңүчеләр!» – дип кычкырыйм.
Яшьлектәге кебек, гармун тартып,
Урам буйлап җырлап үтимме?
«Сугыш адаштырды сөйгәнемне,
Кайтып керер», – диеп көтимме?
Җиңү көне илле яшькә житте,
Сугыш калды минем йөрәктә.
Чәнчеп, кадап ала, посып яши
Күңел куагында – тирәктә.
Аның өлешен дә куярга да
Дусларны табынга җыярга...
Хыянәтсез бит ул минем хәтер,
Юксынып, моңаеп җырларга...
Җиңү көне нурлы, якты, җылы.
Җаным уйный.
Җаным – күбәләк.
Гаҗәпмени, әгәр күз яшьләрем
Көмеш булып тамса, тәгәрәп.

# ИРКӘЛИЛӘР НУРЛАР ДӨНЬЯНЫ

Моңлы, серле, якты язгы көннәр.
Иркәлиләр нурлар дөньяны.
Туңып торган чагы булмагандай,
Яшьлегенә бара җир тагы.
Язгы көндә шундый тойгы миндә:
Җиргә китмәс өчен килдем күк.
Һәрчак булыр кебек умырзая,
Һәрчак көлеп торыр зәңгәр күк.
Кошлар кайтыр кебек китмәс өчен,
Гөлләр чәчәк атар сулмаска;
Җир бизәнә, купшылана кебек,
Эрүләре мәңге туңмаска.
Җан ярсына... Җилкенәдер күңел...
Ачкыч?
Җир күчәрен борырга.
Ходай белә: телим, кешелекне
Сутеп, язгы нурдан корырга.
Куйчы, көйсез күңел, эзләнмәче.
Җир күчәрен борыр ачкыч юк.
Ташкын белән агар берчак чүп-чар...
Кояш – мәңге...
Менәр баскыч юк.
Нурлар хисләремә чиртәләр дә
Нинди гүзәл хыял уйната!
Җир яшьлеге – көч һәм күңел дәрте.
Алда – яшәү.
Тормыш – уйлата.
Җир яз саен яшьлеккә кайта.

## ТОРМЫШ МОҢЫ

*Хакимият башлыгы Нәзир Зыязовка*

Кара урман куе, юллары юк,
Табып булмый эзләп тә көн-төн.
Утырыйкмы әллә сабыр гына,
Данко кебек егетне көтеп.
Ул йөрәген алып уң кулына,
Күтәргән дә яктырткан юлны.
Караңгыга чигенмичә булмый...
Үткәргән бит бу батыр улны.
Данко кебек егет туар, диеп,
Утырыйкмыни һаман көтеп?!
Заман улы урман кисеп килә.
«Юлны ачсак, булыр, – ди, – үтеп».
Кара урман шаулый, ниләр даулый,
Урман моңы яшел тирәктә.
Бәхет яулый егет – юл ача.
Тормыш моңы көчле йөрәктә.
Дуслары да аның белән бара –
Эш сөючән, уңган егетләр.
Егетләре нинди!
Ярсу җанлы...
Нәкъ Нәзирнең үзе кебекләр.
Без яшәгән заман авырлыгын
Җайлап кына алып иңнәргә,
Елгага су, барырга юл эзли,
Якты өметләр күңелләрдә.

Изге ата Нәзиргә кушкан
Тазартырга авыл чишмәсен.
Үсмер чакта ул чистартып торган.

«Эчәр суга чүп-чар төшмәсен»...
Тормыш елгалары саекканда,
Чишмәләрнең табып күзләрен,
Энә белән чокып юлын ача...
Күңелендә ата сүзләре.
«Сайла, улым, эшнең син шундыен,
Кирәк булсын эшең кешегә!»
Ата әйткән сүзләр – якты сукмак,
Ул ярдәмче һәркем эшенә.
Ай һәм Кояш аның йөрәгендә,
Бөтен дөнья сыйган, бар да бар.
Эш сөймәсне генә сөйми җаны,
Ялкаулыкка анда урын тар.
Алар чәчкән иген кырларында
Тук башаклар җыры – моң гына.
Йөрәк җылысында шытып чыккан,
Бөртекләре шуңа мул була.
Аның күңелендә симфония,
Җилләр чиртә бодай башагын.
Тырыш хезмәт биргән олы моңнан
Егет күңелкәе шашамы?!
Юк, юк!
Ипле, сабыр егет икән,
Башын чөя белми күкләргә.
Аның сабырлыгы, чыдамлыгы
Өлге була ала күпләргә.
Хезмәт моңы - көткән тормыш моңы.
Ул яңгырый ерак-еракка.
Сүлпән йөрәккә дә үтеп керә...
Башак моңы шаулый колакта.

Тормыш йөге, ай-һай,
Бик авыр йөк.

Әйбәт юллар кирәк үтәргә.
Юлсыз булу, ике кулсыз булу.
Бәхетле көн каян көтәргә?!
Алар салган юллар көзге кебек,
Машинага – канат. Оч кына!
Күңелеңдә хезмәт моңы булсын,
Үтмә бу юллардан буш кына.
Дөнья йөген тартып үтәр өчен
Нәзирләр бит бара юл салып.
Йөрәк түгел аның уң кулында,
Ялкын чәчеп торган көч бары...
Акыл көче?.
Әйе, акыл көче!
Меңне җиңә торган һәр сүзе.
Аның башта буш хыяллар түгел.
Көләч йөзле булса да үзе.
Күпме өмет, күпме хисләр юлда...
Башкаеңнан күпме уй үтә.
Түгелепләр елар кайгыңны да,
Сабырлыкка өндәр моң итә.
Халык бәхетенә туган Нәзир,
Яше-карты гел игътибарлы.
«Пәйгамбәрләр нәселеннәндер», – ди,
Динче дә аңа ихтирамлы.
«Нефть ата», – дибез. Хисле җанда
Моң бит шулай тулып түгелә.
«Кара алтын», – дибез. Әйе, алтын,
Ак бәхет ул – бәхет күңелдә.
Җир күчәрен майлап торыр өчен,
Кирәк аңа, кирәк карасы.
Шул караны нурга әйләндереп,
Ерак әле, ерак барасы.
Гасырларның төрлесен күргән җир.

Һәр чорның үз нуры,  үз моңы.
Җырларга да көй биргән, моң биргән
Заманның үз улы... үз улы.
Ишетәм: моң ага һавада кич,
Ах, Нәзир баяны тавышы!
Оча моң! Җырламый, елый баян,
Бу – аның йөрәге сагышы.
Имәнгә дә кагыла, аяусыз,
Бу көйсез заманның җилләре,
Йөрәк ярып туа тормыш моңы,
Шуны сөйли баян телләре.
Яшәү рухын саклап калу кирәк,
Каһарманлык Сездән, егетләр!
Чорга тоткын булу –
Хурлык, хурлык!
Әсир булмас Нәзир кебекләр,
Уйна, әйдә, уйна гармуныңны!
Яңгырасын Җирдә Сезнең моң.
Сезнең җырда олы, саф мәхәббәт,
Сезнең моңда сүнмәс якты нур.

## ЭЗЛӘНӘ КҮҢЕЛ

Көн ямансу,
Озын сукыр төн.
Җан тынгысыз, эзләнә күңел.
Үтәсе юлыбыз билгесез,
Күңелләр кайгыдан буш түгел.
Күренә халыкның куллары
Сузылган Тәңрегә ялварып.
Иңсәдә фәрештә канаты...
Хыялы оҗмахка юл алыр.
Ә минем үз көнем, үз Аллам.
Гомергә табындым шагыйрьгә.
Гел генә көч алдым, дәрт алдым
Шагыйрьдән, шагыйрьдән, шагыйрьдән.
О, шигырь!
Бик назлы хыял син.
Җанымның тылсымлы көче син.
Баш бирмәс давыллы буранны
Күңелдән куарлык көчле син.
Кайчакта бик җылы, ягымлы,
(Йөрәкнең майлары эрерлек),
Моңлы бер шигырьнең нурлары
Мең йолдыз нурына торырлык.
Кайгы бар илемдә, җиремдә,
Җыр кирәк күңелгә, шагыйрьләр!
Җаннарны сүнүдән сакларлар
Шигырьләр, шигырьләр, шигырьләр!

## ӨМЕТ БИТ УЛ ҮТМИ

Син генә уемда,
Ничә ел буена...
Кайтырсың шикелле беркөнне.
«Сөям», – дип көйләдең,
«Кайталмам», – димәдең,
Сугышка юл тоткан ул төнне.
Ватылды чын сөю,
Җанымда тик көю,
Мәхәббәт икегә бүленде.
Яртысы – синдарда,
Яртысы миндарда,
Җир шарын бүлгәндәй күренде.
Һаман да сагынам,
Хыяллар кабына...
Тик ялгыз ай гына каршымда...
Ышанмыйм үлүгә,
Сөюем сулуга,
Интегәм, уйланам, ярсынам.
Һәр таңда көтәм мин,
Ник өмет итәм мин?!
«Кайттым бит», – диярдәй тоела.
Юксыну йөрәктә...
Кошым юк тирәктә,
Күңелем буш синсез,
Боегам.

## ДУСЛЫК

«Сине яхшы белгән кеше
яратмый», – дип,
күңелгә боз куйган иде
берчак берәү.
Яратуның сәбәпләре
миллион төрле...
Шөкер инде, туры килсә,
миңгә берәү.
«Син кем? – диеп
сорамыйм бит, –
дустың кем?» – дим,
ә мин шуннан
кемлегеңне
әйтермен», – ди.
Халык – зирәк. Әнә нинди
сизгер булган.
Кемнең кемгә яраганын
төгәл белгән.
Гадел кешене яратмас
ялганчылар,
яки үзен сатып йөргән
уйнашчылар.
Һәрчак гамьсез,
күрми үтәр
моңсыз бәндә,
җырны, көйне
аңламаган
коры гәүдә.
Һич ярарга теләгем юк
намуссызга,
булыр-булмас

эшен күрсәм,
йөрәк сыза.
Очраганда сәлам биреп
тормас өчен,
сукмагым да
андыйлардан
читләп уза.
Яраттым мин
хезмәтемнең
һәр минутын.
Байтак кына
бик уңышлы
эшләр булды.
Чын күңелдән
якын күргән
дуслар белән
киң күңелем, иркен өем,
дөньям тулды.
Саф күңелле,
бар дөньяны
сөйгән кеше,
күңел күзе белән күреп,
яхшы белсә;
Йөрәгеннән урын бирми
тапмас чара,
«Бер яхшыга –
бер яхшы», – дип,
туры килсә.

## ЯҢГЫРЫЙ ЖЫР

Еллар буйлап карап киләм Яңавылны,
Урталыкта туктадым да уйлап торам:
Чатлык саен хәер сорап сузылган кул,
Арба кучәрен кумәрлек баткак урам.
(Күз алдына килеп тора кебек шунда.
Үзем инде китеп барам асфальт юлдан).
Менә сукмак шаулы парк аша китә,
Күз алдыннан мәйдан чагы үтеп бара:
Аяк басар урын юктыр – тулы халык,
Тальян моңы үзәкләрне өтеп ала.
Мәйдан җырлый, мәйдан гөрли, мәйдан елый,
Военкомат ишек алды... сугыш елы.
Рәхмәт әйтәм күңелемнән барысына,
Безнең өчен үзен корбан иткәннәргә.
Бишәр катлы йорттан урам тусын өчен,
Яуда бездән мәңгелеккә киткәннәргә.
Җиңү китерде безгә нурлы ал таң,
Гөрләп торган тормыш үсте Сезнең каннан.
Шул таң нуры дәрт, көч бирә йөрәкләргә,
Бәйрәм белән тулы бүген безнең урам.
Җиңү китергән бәхет чәчкә ата...
Бер бик шаян, бер сагышлы яңгырый җыр.
Бәхетлегә берни түгел салкын буран...
Күңелемдә шат елмая данлы бер чор.

## САРАЙ САЛДЫМ

Гомер буе сарай салдык,
Көн дә салдым... төнгә калдым.
Яшәүгә ямь булсын, дидем,
Ак кирпечтән сарай салдым.
Килде бер көн... Купты давыл.
Сараемны салды сузып.
Күбек булганмы кирпече?!
Ачы җилдә бетте тузып,
Саклый алмадым сарайны,
Көч җитмәүгә әрни күңел.
Сарай салдым. Күбек сарай!
Бушка үтте минем гомер...
Кабат кайта торган түгел.

## ТУЗДЫ ЮЛӘР ЯШЬЛЕГЕМ

Яшьлек чанасында җиләм
Хыялым канатында.
Пар булырдай бер яр эзлим
Йолдызлар арасында.
Күрче!..
Күтәрелде давыл,
Элеп алды чанамны.
Котырынган бу җил-давыл.
Белми һичбер чаманы,
Миллионнарның якасыннан
Бөтереп алды давыл.
Утка – ут!
Җанга – җан!
О, көрәш! Көрәш авыр...
Алыш сузылды озакка,
Буранлап, яшьлек туздыы.
Сугыш давылында мескен
Юләр яшьлегем узды.
Үткәнен сизми дә калдым
Ут-давыл арасында.
Ак чәч белән кайтып кердем
Олылар дөньясына.

## ТАВЫШ БИРӘМ

Без үтәсе юллар һәрчак тайгак булды,
Юл читендә, битлек киеп, язмыш көтте.
Бар дөньяны яратуны байлык санап,
Кояш нурына сыенып, дөнья көттек.
Безнең юллар төпсез упкын аша үтте,
Кыяларга ышыкланып, әҗәл көтте.
Упкын йоткан кешеләрнең сөягеннән
Күтәрелгән кара сөрем җанга үтте.
Безнең көннәр шул сөремнән каралдылар,
Барыр юллар, кайгы басып, тарайдылар.
Бер хыянәт итмәсәң дә бу дөньяга,
Түрәләр гаебен йөкләп, таладылар.
Корбан булган солдат кайта табутында.
Юл чатында сугыш тора, бомба тотып...
Яралы йөрәгем әрни, тама каны...
Юк, булмады гомер юлын тыныч үтеп,
Барасы юл безнең һаман сикәлтәле,
Сирәк-мирәк көн кояшлы, төннәр айлы.
Баш киемен алдын артка гына киеп,
Юл буенда көтеп тора шул ук кайгы.
Кем аралый алыр безне кайгылардан,
Кем киртәләр сугыш юлын акыл белән,
Кемнәр сабак ала белә үткәннәрдән,
Мин шуларга,
Тик шуларга
Тавыш бирәм.

## ОНЫТМАГЫЗ УЛ КӨННӘРНЕ

Җиңеп кайткан көнне авылыма
Бәйрәмнәрне искә төшердек.
Кисмәк төбен җыеп, без ул көнне
Арыш кабартмасы пешердек.
Шатлансак та, елый белми идек,
Күз яшьләре агып беткәннәр,
Шатлык хисен тышка чыгарырлык
Сүзләр дә юк, сүнеп кипкәннәр.
Кочаклаган булдык дус-ишләрне,
Иңсәләргә терәп башларны;
Тәбрикләгән булдык митингта
Җиңү белән карт һәм яшьләрне.
Чабаталы ятим яшь балалар,
Арыкланган ирсез хатыннар,
Сөйгәннәрсез калган уйчан кызлар,
Моңсу күзләр... һаман хәтердә.
Сыер җигеп, җирне ерткалаган,
Иңдә ташып чәчкән чак иде.
Әҗәл авызыннан төшеп калган,
Хәлсезләнеп беткән яз иде.
«Исән җанда өмет бар», – ди әйтем,
Халык сүзе мәгәр хак икән.
Төзәтергә сугыш яраларын
Җаныбызда куәт бар икән.
Терелде ил – күрче:
Тагын җиңү?
Тик сагышлар... таралмый сагыш.
Онытмагыз берүк ул көннәрне,
Сыгылса да сынмаган сугыш.

## БЕЗНЕҢ ЮЛЛАРЫБЫЗ

Чабатасы тишек, шинель ертык...
Күз алдымда шундый солдат бүген.
Таныйсызмы? Безнең әтиләр ул.
Җилкәсендә авыр заман йөге..
Ай-яй, көчле булган кулкайлары!
Өзгәләгән коллык богауларын;
Калкан итеп газиз йөрәкләрен,
Тураганнар зур дошман яуларын.
Салкын суга төштек, утта пештек
Ата салган яшәү юлы өчен!
Бозлар түгел, күктән әҗәл яуды...
Бирешмәде яшәү юлы көче...
Ачы җилләр тынмый... өермәләр...
Җилкәнебез юлын җилгә бирми;
Үзгәртүләр, корылулар бүген
Яшәү юлы чокырларын көйли.
Яшәвебез ямьле, илдә байлык,
Каты таштан безнең юлларыбыз.
Сакланганнар гына исән була...
Зирәк, уяу булсын улларыбыз.

## КҮҢЕЛДӘ ЧЫН СӨЮ БУЛГАНДА

Күк көн дә зәп-зәңгәр була ул,
Кулыңа сайрар кош куна ул;
Син мине: «Кадерлем!» – дигәнгә,
Мин сине өзелеп сөйгәнгә.
Тулган ай гел көлеп карый шул,
Күңелдә тургайлар сайрый шул;
Мин сине: «Батырым!» – дигәнгә,
Син мине: «Матурым!» – дигәнгә.
Кич тула күңелгә зәңгәр моң,
Таң бирә көннәргә алсу нур.
Йөрәктә чын сөю булганда,
Яшәү гел сагышлы шатлык ул.

## ЯҢА ЮЛДАН БАРАМ

Яңа юлдан барам. Җырларымнан
Килер көннәремә сукмак салам.
Еллар йөген алып иңсәләргә,
Тып-тын гына җырлап, китеп барам.
Дөнья көтәм бик катлаулы чорда.
Телен суза утлар төрле яктан...
Гомер юлым бары тик бер тотам.
Качма, күңел. Чыда! Җырны сакла!
Көндез – кояш, төнлә – ай юлдашым...
Юлым авыр, әмма җырлап үтәм.
Көртләр ярып, барам яңа юлдан,
Яңа җыр килер, дип, өмет итәм.

## МИН БЕР ДӘ ҮЗГӘРМИМ

Син үскән урыннар,
Син йөргән болыннар
Яз саен чәчкәгә күмелә.
Арыймын, талам мин,
Ерактан барам мин
Син сөйгән гөлләрне күрергә.
Ул гөлләр инде юк,
Яңарган, яшьләр күп.
Болыннар да хәзер үзгәргән.
Онытмыйм гомергә,
Юксыну күңелдә...
Нигә соң мин бер дә
Үзгәрмим?

## ОНЫТЫЛМАСЫН!

Мәңгелек зур гаделсезлек
бар дөньяда.
Көчсезләрне йотып туена
көчлеләр.
Юккамыни җир убыла,
давыл куба...
Барысы да гаделсезлеккә
үчлеләр.
Көчлеләргә кирәк булса,
сугыш башлый,
ир-егетне, ирексездән
утка ташлый.
Болай да чак яшәп килгән
илнең канын,
кан суырган сөлек кебек,
эчә башлый.
Бер сугыш та сүнми калмый,
берчак тына.
Аксак, сукыр, кулсыз белән
дөнья тула.
Ятим калган балаларның
күз яшеннән
газап, кайгы дәрьясының
яры тула.
Онытылмасын!
Фашистларның ерткычлыгы...
Чит туфракка килеп тапты
каберен дә.
Кемгә кирәк?.. Талаучыны
оныталар,
кирәк түгел каберенең

кадере дә.
Фашистларның үз башына
ашкынуы,
җиңелүе бар дөньяга
фаш булуы –
авыр җәза.
Явызлыкка соңгы сабак!
Кояш нурын капламасын
Сугыш кабат!

## ИРЕК СӨЙГӘН ҖИЛЛӘРНЕ КӨТӘМ

Акыл – байлык. Табигатьнең
Безгә бүләге.
Кара кайгы – сынар өчен
Ачы җиләге.
«Кайгы күрми, акыл керми», –
Дисә дә халык;
Кайгыдан кыела җаннар,
Бу да – бер хаклык.
Тик санарлык бармак белән
Булды шатлыгым.
Бәхетле көннәрне көтеп,
Җитте картлыгым.
Юк, үкенмим, һич үкенмим
Ник туганыма.
Акылга – ач, кайгыга – тук
Җан булганыма.
«Гасыр яшә, гасыр өйрән,
Үләрсең – юләр;
Беркайчан да акыл җитми
Кешегә», - диләр.
Кеше акылы житкән эш
Азмы дөньяда!
Җир тирәли очып яши,
Айга юл ала...
Акылсыз эшләгәннәрме
Атом бомбасын?!
«...Акыл җитми», – дию ченең
Хәтер калмасын...
Гасырлар буе яңгырый
Ирекә таләп....
Хәр яшәргә акыл кирәк,

Кем шуны табар?
Яңа елның ирек сөйгән
Җилләрен көтәм.
Ак бураннар, бәлки акыл
Калдырып китәр...
Акыл гына... бары акыл
Бәхетле итәр.

## КӨТ, ДИЛӘР

Кая барсам, шунда: «Көт!» – диләр,
«Чират җитәр, сабыр ит!» – диләр.
Яшәү калган бары бер тотам,
Гомер җитмәс, диеп, ут йотам.
«Минем язмыш шундый, көтәрмен.
Бик зур чират беткәч, үтәрмен...»
Чиратсыз да җибәрәләр һаман...
Кесә калын булган бүтәнне.

## АЛТЫН АЛКАЛАР

Яратам мин кызлар
Колагында
Алтын алкаларның
Чыңлавын.
Чың-чың, итеп, хәтерләтә
Алар
Таңда сандугачлар сайравын.
Чең-чең, итеп, серле бер моң
Бирә,
Чең-чең, итеп, назлый
Күңелне.
Күзне чагылдырып, нуры белән
Яктырта ул күңел күгемне.

## КӨЗГЕ ГӨЛЛӘР ЯҢА ЯФРАК ЯРА

Әҗәл йөргән сукмакларны күрдем,
Я артыннан, я алдыннан йөрдем.
Күз алдымда күпме җанны алды...
Кеше китте – кара кайгы калды.
«Харап иттең», – диеп елау түгел,
«Газаплардан коткардың», – ди күңел.
Бәхәсләшмим, гамьсез кебек гомер...
Чын уйласаң, һич тә алай түгел.
Әҗәл белән күзгә-күз карашып,
Я җай гына, яки нык талашып,
«Җиңелергә ризамын...» – диеп,
Менеп ятам, ак күлмәкне киеп.
Ә йөрәгем миннән көлгән кебек...
«Сынар өчен шаярттым бит», – диеп,
Тигез генә атлап китә башлый,
Әҗәл тагын минем йортны ташлый.
Нинди көчле йодырыктай йөрәк!
«Әйдә, тор, – ди, – чәй эчәргә кирәк...»
Әйе, якты, ямьле шул быел яз,
Җырчы җанның язда киткәне аз.
Көзге гөлләр яңа яфрак яра,
Чәчкәләрен сөеп, җырлыйсым бар.

## БАЗАР

Әллә niləр сата бүген базар,
Юк нәрсә юк, читтән карасаң;
Алын да ал, зәңгәр, кызылын да,
Ал, әйдә, ал, әнә, карасы...
Сатар иде Айны, Кояшны да,
Ераклар шул, ничек аласы?!
Намусын да сата,
Оятын да...
Тик акчадан кесә кабарсын.
Миллионнар да, меңнәр генә санда,
Андый акча каян табасың?!
Акча, акча?
Кол ясады бүген,
Кимсетте ул адәм баласын.

## АКЛЫК БИЗӘДЕ

Сафлык яуды җиргә,
Пакълек яуды.
Тирә-якны аклык бизәде.
Челтәр шәл бөркәнде куакларым,
Ак карларда челтәр бизәге.
Туй күлмәге кигән усакларны
Имән егетләре күзләде.
Ак чалбарлы, ак тун киеп алган,
Ак мыеклы бүген үзләре.
Ап-ак күлмәк кигән яшел чыршы,
Бала итәкләрен кабартып...
Кара кайгыларны каплады кар,
Минем күңелемне агартып.

## ҮТТЕ ГОМЕР

*Яшь гомерне үтә, диләр,*
*Үткәнен күрсәң иде...*
*Халык җыры.*

Үтте, үтте гомер,
Яшьлек калды.
Калды яшьлек...
Күңел түрендә.
Үтми икән яшьлек,
Мәңге яши,
Япь-яшь була икән гомергә.
Бар дөньяны, шашып,
Сөю булмас,
Язлар кабатланып тормаса.
Хыялларым
Канат какмас иде.
Күңелемдә яшьлек булмаса.

## ҮЗЕМНЕКЕ БАРЫСЫ ДА

Җәй буена бакча карап яшәп яту...
Алла белсен, ничек кенә интекмисең.
Шәһәрдә бит эш юк. Җиңел булыр, диләр,
Нигә ялгыз яшәп яту... ник китмисең?
Ничек ялгыз?! Монда минем балаларым,
Сукмагымда торып калган эзләре бар.
Минем өчен изге булган эшләре бар.
Күңелемдә онытылмас сүзләре бар.
Нигез – икәү бәхет өмет итеп салган,
Үзе киткәч, кайгы тавы булып калган;
Монда үткән гомер, йөрәк ярасы да,
Бик кадерле, үземнеке барысы да.
Яшәр өчен максат кебек бар эшләрем.
Ташлап китсәм, юксынудан мин нишләрмен.

## МОҢЛЫ ИДЕ ЯЗЛАР

Илле биш ел үтеп китте инде...
Җиңү көнен бәйрәм итәбез.
Канлы еллар аша эзлим сине...
Кайтырсың, дип һаман көтәбез.
Әле генә кебек бәхет гөлен
Таң нурында икәү эзләдек...
Кайгы тулы заман җилләренең
Әчелеген дә бит сизмәдек.
Сандугач юк күңел талларымда,
Әле гомеремнең көз чагы.
Ләкин хәтер сөеп саклый һаман
Синең белән үткән яз аен.
Матур иде язлар, моңлы иде,
Елмайгандай иде бар дөнья.
Минем күңелемә китмәс өчен
Кереп калган икән ул еллар.

## КҮҢЕЛЕМӘ ЮЛ ЯБЫК

Серле хисләргә буйсынып,
Икәү үбешкән идек.
Гомергә бергә булырга
Сүзләр куешкан идек.
«Инде башканы сөям», – дип,
Киттең язмыш юлыннан.
Сөюемнән истәлеккә
Улым калды кулымда.
«Бик юксынам, кайтам», – дисең,
Үткәнне булмый табып.
Серле хисләр өзгәләнде,
Күңелемә юл ябык.

## ЯФРАКЛАР

Яфракларның гомеркәе бары бер җәй,
Җиргә ява сары яфрак, кызыл яфрак.
Җәй көнендә яшел булып яшәде дә,
Көз көнендә ята җирдә, булыр туфрак.
Агачларның кәүсәсенә төште күзем.
Яшь түгәләр яшь ботаклар, әйтми сүзен.
Мәңгелеккә аерылу авыр шул ул,
Гомерлеккә сагыш кала, бирсен түзем.
Тик бер җәйлек гомерендә, гүзәлкәем,
Нинди бизәк булды җиргә яшел яфрак!
Кешелекле, бик ярдәмчел алар һәрчак.
Яфраклардан сулар һавам була сафрак.
Тик бер бөртек яшел яфрак кадәр генә
Файдам тисә туган җирем – кадерләмә,
Кирәк түгел бушка үткән озын гомер,
Тып-тын гына ятар идем каберемдә.

# КӨТ СОЛДАТНЫ

Бик сагындым кара күзләреңне,
Җәйге нурда янган йөзеңне.
Йөрәгемнең маен эретерлек
Җанга җылы, татлы сүзеңне.
Көт солдатны, кайтам, түз инде.
Синең уйчан, көләч күзләреңдә
Тик үземне күрәм, үземне.
Иркәм, син дә минем күзләремдә
Күрәсең бит бары үзеңне.
Күп калмады. Кайтам, түз инде.
Менә тагын сүзләр белән генә
Үбеп калам алсу битеңне.
Яшәү яме, иркәм, уртак булсын,
Минем сукмагымнан үт инде.
Сөюемне сакла. Көт инде.

## КӨМЕШ АЙ КӨЛӘ

Саумы, кеше!
Саумы, якты дөнья!
Көнең нинди бүген? Ни килә?
Керсез, дөньям, гүзәл табигатең,
Ап-ак карда энҗеләр көлә.
Ак карында кара эз калдырып,
Мәкер йөри таптап дөньяны.
Киләчәккә алмачы аны?
Җиркәемнең гүзәл табигате
Җир күтәрә бит ул. Ни булса да
Яшәр, кайгыларга карамас.
Тигезсезлек җирдә...
Эшсезләр күп...
Авыр кайгы аның башында.
Җир булып, Җир сабырлыгын җуйды,
Тетрәнә язмыш каршында.
Сау бул, Кеше?
Сау бул, якты көнем?
Менә тагын кара төн килә.
Куе күккә тезгән йолдызларын,
Моңсу гына
Көмеш Ай көлә.

## ИМӘН

Имән булып, имән яфрак койган
Салкын җилгә тәнен шәрә куйган.
Нигә, ди, купшылык кышкы көндә...
Көчле булсаң, җитә, шуны тойган.
Ә шулай да имән игән башын,
Ул кыш көтә. Юк, юк! Түкми яшен.
Ботакларын чиртеп ачы җилләр,
Үзе көен көйләп, үтәр кышын.
Нинди тыйнак яши белә имән!
Мин – бик әйбәт, син – начар, дими ул.
Көрәшергә чыкмый, җиңелми дә,
Алдау, алдануны һич белми ул.
– Без – бөек, – дип мактанудан туйсак,
Дөреслек алдында башны исәк;
Кешегә: «Туган!» – дип дәшәр идек.
Имән кебек горур яшәр идек.

## ҖЫРЛЫЙСЫМ БАР

Әҗәл белән күзгә-күз карашып,
Я җай гына, яки нык талашып,
«Җиңелергә ризамын», – диеп,
Менеп ятам ак күлмәкне киеп.
Ә йөрәгем, миннән көлгән кебек,
«Сынар өчен шаярттым бит», – диеп,
Тигез генә атлап китә башлый.
Әҗәл тагын вакытлыча ташлый.
Чынлап та бит, бигрәк ямьле бу яз,
Җырчы җанның язда киткәне аз.
Күзге гөлләр әле яфракталар,
Чәчәкләрен сөеп җырлыйсым бар.

## АК БӘХЕТЛӘР КИТЕР

Тып-тын гына ява мамык карлар,
Ак юрганга төрә җиремне.
Йортлар, сарайлар да ак бүрекле,
Ак бәхетле итче илемне.
Күңел көткән якты көннәр китер,
Сафлык булып җаннарга тулсын,
Бәхет бөртекләре ак кар булып,
Безнең иңбашларга да кунсын.
Ачы җилләр алып килмә, яшь җил!
Бәхет бөртекләре тузмасын.
Тунсыз калып, җимеш агачының
Йөрәк майкайлары сызмасын.
Үткән елның кара кайгы эзен
Язгы ташкын белән юарсың.
Күңелләргә кунган шикле уйны
Җылы җилең белән куарсың.
Сайлама бүләккә алтын тәхет,
Алтын таҗга китми исебез.
Без бит табигатьнең җанлы гөле,
Кояш нуры белән көчлебез.
Ап-ак җәймә җәйдек синең юлга,
Рәхим ит, яшь ел, көтәбез!
Булчы изгелекле,
Бул кояшлы,
Синнән бәхет өмет итәбез.

## ЙОРТЫМНЫ ТУЗДЫРЫП КУЙМАСЫН

Өйләнешкәч, без йорт төзеп кердек,
Сөю хисен салып нигезгә.
Эссе нурдан, җил-давылдан саклый
Бәхет храмыдай ул безгә.
Гомер буе яшәр өчен, диеп,
Мәхәббәттән үрдек бурасын.
Картаюны сизми, йортым ять-яшь,
Үзем кебек чыдам, күрәсең.
Кояш нурларының төсен алып,
Тыштан буяп куйдым сарыга.
Алты почмаклы шул авыл өе
Көлеп торсын, дидем, барына.
Менә ничә еллар, сыңар калып,
Истәлекләр язам шул йортта.
Юк, ялгызым түгел,
Һаман икәү,
Күңелдән китми ул минут та.
Икәү яшәргә, дип, йорт төзедек,
Мәхәббәттән үреп бурасын.
(Җанда шик тудыра заман җиле,
Әллә нинди бит ул, уйласаң...).
«Яратышу чыкты модадан», – дип,
Йортымны туздырып куймасын.

## НИ БУЛДЫ СОҢ?

*Радик Гәрәевкә багышлыйм*

Түбә өстемдә бик зур якты йолдыз
Минем күз алдымда йомылды.
Галәм киңлегендә кара чокыр
Хасил булган кебек тоелды.
Уртак булды язмыш йолдыз белән,
Син дә якты янып, тиз сүндең,
Көчле давыл сине аудардымы?
Койма яңгырданмы син сүндең?
Белә идем сине – яшен ташын,
Гомер буе яшьнәп яшәдең.
Ни булды соң? Нигә яшен булып,
Язмыш түбәсенә төшмәдең.

## САУМЫ, КОЯШ!

Саумы, Кояш!
Саумы, якты дөнья!
Көнең нинди бүген? Ни килә?
Керсез синең гүзәл табигатең,
Ак карыңда энҗеләр көлә.
Энҗеләрдә кара эз калдырып,
Мәкер йөри таптап дөньяны.
Яле, язмыш!
Күрсәт кодрәтеңне?
Киләчәккә алмачы аны.
Җиркәемнең гүзәл табигате
Кара кайгы белән аралаш.
Җир күтәрә бит ул. Ни булса да
Яшәр. Кайгыларга карамас.
Хыянәт бар җирдә...
Кан коешлар...
Авыр кайгы аның башында.
Җир булып, Җир сабырлыгын җуйды,
Тетрәнә язмыш каршында.
Бу дөньяның гүзәл табигате
Кара кайгы белән аралаш.
Язлар килер. Тагын гөлләр үсәр,
Үсәр. Кайгыларга карамас.

## МИНЕМ ТӘРӘЗӘМНЕ КАГАРСЫҢ

Җырым булды юлдаш озын юлда...
Төшкә керде сөйгән яр кебек,
Күңелдәге моңга кушыла да,
Әйләнә ул шунда сер булып.
Истән чыкма әле, назлы моңым,
Синсез авыр булыр юлларым.
Татлы хыялларым сезгә бәйле...
Әй, җырларым!
Яшьлек җырларым?
Ләкин беләм, күпме сулар акты?!
Еракларга үтте күп җилләр.
Кызлар күңеленә кучә бугай,
Мине ташлап китә ул җырлар.
Яшьлек җырын яшәтәсеңме, җил?
Беләм, иренмәссең, карарсың.
Табылсалар, шундук хәбәр биреп,
Минем тәрәзәмне кагарсың.

## НАФТАЛАНДА

Клумбага карап сокланганда,
Чәчәкләре миңа елмайганда,
Исләреннән рәхәтләнә җаным,
Канәгатьлек тоя бөтен тәнем.
Әмма уйлар бер дә монда түгел.
Туган якларымда йөри күңел.
Чәчкә уртасында әнкәм йөзе,
Елмайгандай итә, сөйли үзе.
Зәңгәр бизәк төшкән ак күлмәге,
Ак яулыгы, имеш, башында.
Гөлләр уртасында, дулкынланып,
Гел елмаеп тора каршымда.
«Дөрес, мин җирдә юк.
Ә яшим бит.
Кайда булсаң, балам, мин шунда.
Авыр түгелме, – ди, – чит җирләрдә,
Ничек үтә көннәрең монда?»

## СОЛДАТ ЙОРТЫ

Илле биш ел... көтү җиңел эшме?!
Агач йортлар инде муртайды.
Өчәр солдат биргән анакайлар
Танымаслык булып картайды.
Онытмыйлар Сезне, Сез яшисез,
Сезнең каннар безнең тамырда.
Ил бәхете өчен көрәштегез,
Илгә бирдегез сез барын да.
Син бирмәсәң әгәр гомереңне
Киселә иде илнең гомере...
Синең төсең итеп саклый булыр
Иске йортны анаң күңеле.
Үтеп барган җирдән туктап калдым
Тәрәү салган бу йорт янында.
Солдат йорты... Ялгыз ана һаман
Улын көтә тәрәз янында.

## СИНЕҢ АЛДА ЗАМАН СЫНАУЛАРЫ

Балачакта нәфис, йомшак идең,
Күңелемнән кая куймадым!
«Яшәүгә юл сала алмый торган
Бала булмасмы», – дип уйладым.
Үсә төшкәч, тормыш киртәләрен
Үзең тотып, үзең атладың...
«Гамьсез булдың», – димә, мин күзәттем,
Төннәрен дә керфек какмадым.
Мин бәхетле чая кызым белән.
Әмма тыныч түгел күңелем.
Синең алда заман сынаулары
Күреп торам җиңел түгелен.
Сиңа төшкән тормыш авырлыгын
Иңсәм белән торсам күтәреп,
Бик шатланып өмет итәр идем
Сукмагыңнан җиңел үтәрең.

## НАҖАР НӘҖМИ ИМӘНЕ

*Н.Нәҗмигә – 75 яшь*

Гомер юлы ташлы-таулы...
Җайлы җирен күрмәгән.
Юл чокырын үткән саен
Наҗар үргә үрләгән.
Калкансыз күкрәгенә
Каккан җилнең төрлесе,
Ләкин һаман имән җанда
Бүрткән чәчкә бөресе.
Кояшлы көннең берсендә
Наҗар утырткан имән.
"Җан сөйгән агачым Җирдә
Истәлек булсын", - дигән.
Давыл ботарламак булган
Ботакларын имәннең.
Наҗар холыклы яшь имән
Давылга баш имәгән,
Зәңгәр күккә үрләгән.

# ЯЛГЫЗ ЙОЛДЫЗ

Зур Кояшка карап сәфәр чыктым –
Кояш батты. Җирне Ай күзли.
Җем-җем итә. Күз кысалар күкнең
Шаян егетләре – йолдызлар.
Һәрбер җанның үз өлеше, диләр,
Кайсы икән минем йолдызым?
Кояш һәм Ай нурын юлдаш итеп,
Китеп барам эзләп ялгызым.
Хыял күперенә күтәреләм.
Тылсымлы тай менгән аткынам.
Алып кайтыйм мәңге янар утны,
Сакламасмы ачы салкыннан.
Акыллы Ай серле генә көлә,
Көмеш нурларына чиертә:
«Заман җилләренең салкынына
Ялгыз йолдыз булалмый киртә».

## БӘХЕТ КИБӘННӘРЕ ЮЛЫҢА

Икмәк елы авыр.
Ай, катлаулы!
Кыл күперләр аша үтәсе.
Игенчегә, берне меңгә ярып,
Бөртекләрдән диңгез итәсе.
Үзе чәчкән иген сусый калса,
Яна, көя аның йөрәге.
Күз яшьләре тама кайчагында,
Көзге яңгырларга ияреп.
Алтын бодай,
Ак мыеклы арыш –
Игенченең иркә җимеше.
Күңел җылысында кабартылып,
?стәлемә биргән күмәче.
Батырлар сез. Рәхмәт яусын сезгә.
Бәхет кибәннәре юлыңа!
Тылсымлы дәрт бирсен,
Бетмәс көчләр
Иген иккән корыч кулыңа.

## ЕЛМАЮЫ – ДӨНЬЯ ЯМЕ

*Башкортстанның атказанган артисты*
*Рафаэль Галиевка – сүз остасына*
*багышлыйм*

Җитмеш тугыз узды. Кара көйгән
Кайгы элеп минем гомергә.
Мең дошманның йөз ел эшли алмас
Хәсрәтен куйды күңелгә.
Үз йортына киләм – килен ялгыз,
Әткәй йорты – анда да ул юк.
Эш бүлмәсе – башка кешенеке,
Афиша бар – сәхнәдә ул юк.
Фотолары ята өстәлемдә,
Сөйләшергә булмый – сүзе юк.
Пөхтә итеп элгән киемнәре,
Эчләрендә көләч үзе юк.
«Елмаюы – дөнья яме, – диләр, –
Гаҗәп көчле, – диләр, – һәр сүзе».
Татарларның күңел күкләрендә
Яши торган сәнгать йолдызы,
Табигатьтә нинди гаделсезлек!
Аталарның җанын яндырып,
Басса тимер өзәр ирләр китә
Үсеп житмәс уллар калдырып.
Якты дөньям, дөнья кирәгем бар.
Һаман шатлыгым юк, көем юк.
Җырыма моң, яшәүгә ямь биреп,
Янып торган көләч энем юк.

## КҮҢЕЛЕМНӘН МӘҢГЕ КИТМӘССЕҢ

Юк инде, юк! Кирәк түгел синнән,
Кышын тюльпан эзләп интекмә.
Умырзая үскән яз көннәрен
Онытмасаң, миңа шул житә.
Бернәрсә дә көтмим бит мин синнән,
Барлыгыңны белсәм, шул җитә.
Синең яктан искән таң җиле дә
Ярсу йөрәгемне җилкетә.
Юк инде, юк! Вәгъдә итмим сиңа,
Уртак таңнар назын көтмәссең.
Исеңдә тот: яшьлек яме булып,
Күңелемнән мәңге китмәссең.

## ЙӨРӘГЕМДӘ КАЛДЫ ЭЗЛӘРЕ

Сөюеңнән шашып, канатланып,
Очып йөрүеңне онытмыйм.
«Сөясеңме?» – дидең, мин оялып,
Янып төшүемне онытмыйм.
Мин яратып сиңа карап тордым,
Елмайдың син, аңлап күзләрдән.
Ялкынланган чагы сөюемнең,
Көчле иде хисләр сүзләрдән.
Өметләрем бер көн күккә очкач,
Әрнеп, юксынуны онытмыйм.
Яшәү ямьсез, көн күңелсез иде,
Кояш нуры үтмәс болыт мин...
Җаным аша үтте инде бар да,
Йөрәгемдә калды эзләре.
Мәхәббәттә яну-көюләр дә
Ялкытмыйлар икән үзләре!

## ЯҢА ЯЗДА

Карлар эреп, ерганаклар агачак,
Салкын көннәр артта торып калачак.
Ал күлмәкле яңа таңнар туачак,
Җир яшәреп, яшьлегенә барачак,
Яңа язда яңа гөлләр үсәчәк.
Язмыш безгә тагын нәрсә бирәчәк,
Көткән бәхет безгә язмы киләчәк?
Кара кием кидермәсме күрәчәк?
Кичтән киткән кояш иртән киләчәк,
Көлеп, күктән нурын җиргә сибәчәк.
Орлыклары көзен кипкән гөлләрнең
Беләм: тагын яңа шытым бирәчәк.
Безнең җаннар
Сөя язгы көннәрне,
Терелерме
Шиңгән күңел гөлләре?..

## УЗЫША ЯШЬЛЕК

Яши белми минем күңел
Килешеп яше белән,
Тынгы белми, бәхәсләшә,
Узыша яшьлек белән.
Яшь гомер очкынын өреп,
Күретмәкче күңелем.
Яшьлек уты кабат янмый,
Сизми мөмкин түгелен.
Күңел тәрәзәсен чиртеп,
Җилләр бит моң уйната.
Яңа таңнар күңелемдә
Яшәүгә дәрт уята.
Йөк тартырга булышыйм, дип,
Эшкә көйләнә күңел.
Гомер юлын башлар өчен
Аяк киенәм кебек.

## ЧӘЧКӘ САЛАМ СЕЗНЕҢ КАБЕРГӘ

Фатих Кәрим сөйгән чәчкәләрдән
Букет саклыйм күңел түрендә.
Дим буеның ал гөлләрен үбеп,
Җырлап ята кебек бүген дә.
Хат ташучы кызны күргән саен,
Муса Җәлил кайта күңелгә.
Җиңү көне белән тәбрик итеп,
Хат җибәрер кебек бүген дә.
Хатлар килмәс...
Явыз сугыш йотты.
Күңелләрдә исән Сезнең моң.
Булмый бит ул җырны җиргә күмеп,
Моңны юк итәр көч бармы соң?!
«Соңгы сугыш. Башка яу булмас», – дип,
Өметләнеп кердек бит утка.
Чәлпәрәмә килде безнең өмет,
Бомба яудыралар өметкә.
Туздырылды Ватан. Яра арта...
Кемнәр бәйләр йөрәк ярасын?
Кем дус?
Кем дошман соң, танымыйбыз.
Кемне җиңеп, кая барасы?
Гафу итегезче, шагыйрьләрем!
Сез, мөгаен, бездән бәхетле.
Кабер – тынлык.
Кабат күрмәдегез
Сугыш таҗы кигән тәхетне.
Кыска гомерегез - озын зур моң,
Яңартасыз безнең бәгырьне.
Сез лаеклы мәңгелек кадергә,
Чәчкә салам Сезнең кабергә.

## САГЫНАМ

Болындагы йомшак җилләр
Чәчләремә кагыла.
Башымны сыйпап яраткан
Чакларыңны сагынам.
Кояш калка, керфек суза,
Алтын нурлар агыла.
Кояш нурларыдай җылы
Карашыңны сагынам.
Таңда сайраган былбылның
Моңы җанга сарыла.
Әзләнә күңел, юксынып,
Һаман сине сагынам.

## КӨЗНЕҢ КӨМЕШ КӨННӘРЕНДӘ

Агачлар матур бизәкле,
Я кызыл, я сап-сары.
Күңелләргә сагышлы моң
Сала торган чаклары.
Кошлар тавышын ишетәм
Көмеш күгендә көзнең...
Саубуллаша... яулык болгый,
Исәнлек теләп безгә.

## БУРАННАР ҮТКӘН САЕН

Ачыйм әле сукмагымны
Олы юлга җиткәнче.
«Юл юк икән йортына», – дип,
Дуслар керми китмәсен.
Олы юлга чыксын сукмак,
Кар көртләре күммәсен.
Ачмыйм юлны кайгыларга,
Шатлык – күрми китмәсен.
Яшәү сукмагымны ярам,
Бураннар күмгән саен.
Бәхет көтәм.
Сукмагымнан керер табып,
Бер җаен.

## СИҢА

Әлләниләр көтмим, көтмим синнән,
Кышын лалә эзләп интекмә.
Умырзая үскән яз көннәрен
Онытмасаң, миңа шул җитә.
Су буенда таллар җырын әгәр
Хәтерләсәң, миңа шул җитә.
Синең яктан искән таң җиле дә
Ярсу йөрәгемне җилкетә.
Бер нәрсә дә вәгъдә итмим сиңа,
Уртак таңнар назын көтмәссең.
Тик шуны бел: яшьлек яме булып,
Күңелемнән мәңге китмәссең.

## АЛЛА КАЙТТЫ

Ул чиертә йөрәк кылларына,
Ачыйм тәрәзәсен күңелнең.
Ходай каһәреннән башка гына
Үтмәбезме калган гомерне.
Алда кушмаган эш эшләнмәсә,
Җир йөзендә җаннар сафланыр.
Җаны саф булганда, бәндәләр дә
Алла сугуыннан сакланыр.
«Уф, Алла! – дим, –
Ходай күрсәтмәсен...
Алла бирсә, булыр бары да...»
Юлга чыгам.
Алла миңа юлдаш.
Юлым уңсын берүк тагын да...

## ИЛЛЕ ЯШЬЛЕК ЕГЕТКӘ

Илле яшьлек егет бу заманның
Хыялларда туган үрнәге.
Илле яшең белән, уңган егет!
Җиңел яула яңа үрләрне.
Ак төннәрне эзләп китмәгәнсең,
Туган җирдә калдың җай көтеп.
Көйсез заман, кара төннәр килгәч,
Йөрәгеңне элдең ай итеп.
Челтер-челтер көйләп, бәхет теләп,
Чишмә ага урман буенда.
Суы салкын, мәхәббәтең - ялкын,
Яшьлек эзең монда уелган.
Борма юллар, күкрәп үскән кырлар
Сезгә сөю йөртә күңелдә.
Җитсә зәңгәр кичләр, кабына хис,
Мәхәббәтең нурга күмелә.
Янып, шашып сөя бар дөньяны,
Ярата ул эшчән иптәшне.
Сокланырлык, таң калырлык кеше,
Кем соң аны, кем үз итмәсен?!

## КАПКА ТӨПТӘ ГЕНӘ КАЛЫЙММЫ?

Зәңгәр күкле, якты, моңлы булып,
Нурлы булып килә бездә яз.
Кояш йөзә, көлеп, серле генә,
Ә җир көтә кебек сөю, наз.
Язгы нурлар авыл кешеләрен
Хезмәт дәрте белән уята.
Кырлар дөньясында үзгәрешләр...
Яңа матур уйлар уйлата.
Ничек ярдәмләшим игенчегә?
Җырлар җырлап, алдан барыйммы?
Я, карчыклар кебек, теләк теләп,
Капка төптә генә калыйммы?
Дога кылыйм. Сезгә уңыш теләп,
Җирне ал-гөл иткән батырлар.
Сезнең шатлык, безнең шатлык булып,
Илгә байлык булып кайтырлар.

## АКЫЛ КИТӘР БЕЗГӘ, ЯҢА ЕЛ!

Кояшлы көн, айлы төнең белән,
Нурлы йөзең белән кил безгә.
Күчтәнәчең булыр балаларга...
Бәхет сорап,
Мин дә сузам кул.
Бәхетсезлек – һаман кан коюлар.
Бәхетсезлек – хаклар артуы.
Туган җирне сату... О, хыянәт!
Тигезсезлек кире кайтуы...
Сорамыйбыз, гел яз китер, диеп,
Булыр елның көзе, кышы да.
Өши күңел ачуланышудан,
Булсын җанның бик күп дусы да.
Җанга җылы китер, рухи көч!
Кыш салкынын булсын җебетеп.
Күңелләрдә каткан калын бозны
Агызырлык булсын, эретеп.
Яңа елым!
Безгә акыл китер?
Һәммәбезгә булсын җитәрлек.
Акылсызлар явын юл яздырып,
Яшәү йөген төяп үтәрлек.
Әй, Ходаем!
Булчы изгелекле?
Яңа елга ярдәм кулың суз,
Яңа елның ак карлары кебек,
Саф күңелле,
Ак булыйкчы без?!

## СӨЮ ТҮРӘ ХӘЗЕР КҮҢЕЛДӘ

Сөю бит ул – учка алган коштай,
Кысып тотсаң, һәлак итәсең.
Гамьсез булып, учың ачык булса,
Беләсеңдер очып китәсен.
Мәхәббәтне юкка гынамыни
Тиңлиләр бит утка, ялкынга.
Янып бетеп, көлгә калмас өчен
Чумалардыр суга, салкынга.
Ә мин мондый хәлгә чыдамыйча,
Мәхәббәттән китеп «котылдым».
Әсир төшеп кырыс горурлыкка,
Ялгызлыкка килеп тотылдым.
Чара түгел икән ялгызлык та,
Сөю түрә хәзер күңелдә.
Инде күпме сагышланып янам...
Тынгы бирмәс, ахры, гомергә.

## ТӨШӘ КАР БӨРТЕКЛӘРЕ

*1996 елда 12 декабрьда гына*
*кар төште*

Шатлык ява! Ява карлар...
Карсыз кышта нинди ямь!
Кышлар нурлы, якты була
Ап-ак карлары белән.
Карлы кышның күңелендә
Дөнья сере саклана.
Киләчәктән көткән бәхет
Ак кар белән каплана.
Кемнәр генә көтми карны
Чаңгыда очар өчен.
Кошлар белән узышырга,
Сынап карарга көчен.
Чаңгылар, чаналар эштә,
Төшә кар бөртекләре...
Кар тавына кунар бүген
Уралтау бөркетләре.

## КҮҢЕЛ КОШЫМ

Җанга якын кешем – күңел кошым,
Әй, яшьлекнең ерак йолдызы!
Үз йөрәгебезнең хисләр көче -
Дөнья гүзәллегедер үзе.
Әле генә кебек, бәхет гөлен
Таң нурында икәү эзләдек...
Кайгы тулы заман җилләренең
Әчелеген дә бит сизмәдек.
Сандугач юк күңел талларымда,
Әле гомеремнең көз чагы.
Ләкин хәтер сөеп саклый һаман
Әллә кайда калган яз чагын.
Матур иде язлар, моңлы иде,
Елмайгандай иде бар дөнья.
Минем күңелемә китмәс өчен
Кереп калган икән ул еллар.

## САМАНТА КҮПЕРЕ

Океанга күпер салды Саманта,
Тоташтырып күңелләрен илләрнең.
Нәни кулын сузды нәни дусларга,
Ак чәчәкле язлар теләп җирләргә.
Күпме яшьләр килер шушы юллардан!
«Саманта иленнән сәлам!» – диярләр.
Илебезнең ал чәчкәле гөлләрен
Аның кебек чын күңелдән сөярләр.
Салават күпере салды кыз бала,
Кояшның һәм айның җыеп нурларын.
Изге теләк белән тулы бу нурлар,
Яктыртырлар Җирнең барыр юлларын.

## ЯВЫЗЛЫК БАР

Өй артымда гөлләр чәчкә атты,
Дөнья ямен тояп, җәй кайтты.
Давыл купты, чытырдады яшен...
Күңелемә серле шик япты.
Яңа җәйнең япь-яшь, дәртле чагы,
Өмет белән тулы кочагы...
Кемнәр анда очкын чәчә Җиргә?
Кабынмасмы Җирнең учагы?!
Җәйнең олы сые – иген үсә,
Өлгертер дә тиздән иплә ул.
Явызлык та үсә...
Дөнья ямен
Тоя белми торган хикмәт ул.

## КОМСОМОЛ – КӨЧ

Комсомол – көч, безнең горурлык,
Анда берәү бишкә торырлык.
Анда сафлык, анда бетмәс дәрт,
Елгаларны кире борырлык.
Комсомолда – яшьлек ташкыны,
Гомер юлы шуннан башлана.
Анда ялкын, анда мәхәббәт...
Таулар юлы шуннан баш ала.
Комсомолдан үтте юлларым...
Эзләремнән килә улларым.
Алар матур, тиңсез кыюлар!
Йолдызларга торткан юллары
Олы юлда торса, тауны да,
Белеп торам ярып үтәрен.
Кирәк булса, җирнең үзен дә
Китәр кебек алар күтәреп.
Безнең өмет, безнең таяныч.
Яшьлек җыры гүзәл комсомол.
Хәерле юл Сезгә тормышта!
Мәңгегә яшь, батыр комсомол!

## ЯЗЫЛМАГАН ЗАКОННАР КҮП

Илебездә закон... закон...
Ул өр-яңа.
Язылмаган законнар да
Күп дөньяда.
Җирдә юкны бар итүче
Без – үзебез,
Үзебездән... кара яки ак
Йөзебез.
Мәскәү килеп иген чәчмәс
Безгә юк, юк!
Үзебезгә әле йортлар
Саласы күп.
Саклар закон явызлардан...
О, сирәктер...
Язылмаган закон монда
Бик кирәктер.
Саф йөрәкле, чиста куллы
Кеше генә,
Янып-көеп яшәсә ул
Эше белән,
Утырмаса, бала кебек,
Ярдәм көтеп,
Яши белсә, авырлыклар
Аша үтеп,
Шунда гына барлык закон көчле була,
Язылмаганы язылган төсле була.

## КАЙТАМ ӘЛЕ

Кайтам әле туган ягыма,
Бодай пешкән кырлар таңына.
Балачакта җанга наз биргән
Болын чәчәкләре янына.
Кайтам әле үскән ягыма,
Көмеш сулы чишмә ярына.
Итәгендә гөлләр үстергән
Җир җиләкле таулар янына.
Кайтам әле, кайтам авылга,
Күңел тарткан дуслар янына.
Чәчәкләре җиргә баш игән
Әнкәм яткан кабер янына.

## АБЫСТАЙ

Коммунистлар мулла булды,
Гаҗәп хәл бу дөньяда.
Мәчет белән иман кайта
Иман кайта дөньяга.
Авыз ачарга җыйдылар,
Озын өстәл тутырып.
Майбәдәргә сүз бирделәр,
Сөйли авыз тутырып:
«Вәгаземә кушып сөйлим,
Үткән динсез көннәрне.
Партионный түгел хәзер,
Укып чыгам төннәрне.
Мин – абыстай инде бүген,
Ачылды минем күгем.
Ашка йөрим, Корьән укыйм,
Бәхетле үтә көнем».

## КҮҢЕЛ КЫЛЫМ СЫНДЫ...

Нинди еллар үтте безнең баштан...
Канлы юлдан бәхет эзләдек.
Гомер буе язмыш каршысында
Бөгәрләнеп тордык, тезләнеп...
Язмышыма каһәр телим бүген,
Күңел кылым сынды, түзмәде.

## АКЛЫК БИЗӘДЕ

Сафлык яуды җиргә,
Пакълек яуды.
Тирә-якны аклык бизәде,
Челтәр шәл бөркәнде куакларым,
Ак карларда челтәр бизәге.
Туй күлмәге кигән усакларны
Имән егетләре күзләде.
Ак чалбарлы, ак тун киеп алган,
Ак мыеклы бүген үзләре.
Ап-ак күлмәк кигән яшел чыршы,
Бала итәкләрен кабартып...
Кара кайгыларны каплады кар,
Минем күңелемне агартып.

## ЯРАТУНЫ БИРӘМ ТАРАТЫП

Миннән дә бай тагын кем бар җирдә...
Күңелкәем тулы саф сөю;
Кайгыларым, шатлыкларым да бар,
?йдәш анда яну һәм көю.
Яратуны, бөртекләргә бүлеп,
Бирим әле сезгә таратып;
Тагын мең ел яшәсәм дә җирдә,
Бетерә алмам, ахры, яратып.
Бөртекләрне йөрәк түрегездә
Үстерерсез саклап, кадерләп;
Миннән күчкән шушы олы хисне
Каян килгәнлеген хәтерләп.
Игенчегә бирәм иркен кырлар,
Чәчәк тулы яшел болынны.
Юлчыларга бирәм үтми калган
Хыялга бай гомер юлымны.
Эшчеләргә булсын башланмаган
Дөнья кадәр гүзәл эшләрем.
Акылларын җигеп, эшләр алар
Һичбер кызганмыйча көчләрен.
Иң зур өлеш булсын балаларга...
Безнең дәвам – зур киләчәксез!
Бар дөньяны без сөйгәнчә сөеп,
Янып-көеп яшәячәксез.

## ЭЗЛИ КҮҢЕЛ

Гомер юлына таш җәеп
үткән, диләр...
Нинди күркәм эш бит, әгәр
шул чын булса.
Авыр юллар җиңеләйгән
булыр иде,
янында бер ышанычлы
юлчы булса.
Дөнья матур. Кыш артында
язы да бар.
Язгы нурдан нидер көтә,
эзли күңел.
Гомер юлын алтын белән
түшәсә дә...
Ялгыз җанга яшәү яме
тулы түгел.
Гомер буе нидер көтеп,
талган йөрәк:
«Гомер үтте, вакыт җитте, – ди, –
ял кирәк...»
Ә күңелнең үтми гомере,
вакыты.
Аңа һаман олы юлдаш – бер
яр кирәк.

## НИГӘ ӨЗДЕМ?

Сагышларны салып булмый суга,
Күңелеңне күмеп торса да,
Син йөргән ярдан инде күптән
Эзләреңне дулкын юса да.
Сагынганда таңны каршы алам,
Иртәнге нур күңел яңарта.
Таң җиле дә шифа түгел икән,
Сагышымны гына кабарта.
Болыннарга чыгам, чәчкә өзәм,
Күңелем яраткан ислесен.
Нигә өздем?.. Шундый моңсу карый
Син яраткан зәңгәр төслесе.

## ТЕЛӘМИ БОЗЫКЛЫК

Көч алып анадан,
Наз алып анадан
Үсәләр җиребез уллары.
Кыюлык – анадан,
Акылы – анадан,
Яшендәй йөгерек уйлары.
Зур тормыш агачы,
Бу бәхет гөлләре
Аналар сөтеннән шыттылар...
Көмеш су чыңнары,
Таң җиле моңнары
Аналар күңелен чиртәләр.
Кояшсыз булса көн,
Давыллы булса төн,
Шомлана, аналар йөрәге.
Аналар кимсенә:
Уллары белмәүгә
Дөньяга мәрхәмәт кирәген.
Язларның яктысы,
Күзләрнең шатлыгын
Ул көтә балалар кулыннан.
Тели ул саф күңел,
Мәрхәмәт, изгелек...
Теләми бозыклык улына.

## СИН АВЫРСАҢ, МИН ҮЛӘМ

*Бибигөл апама*

Син борчылсаң, мин кайгырам,
Син шатлансаң, мин көләм.
Кайсы көнне минем янда
Дөнья көтәсең геләң.
Безнең күңел игезәктер,
Гел бер төрле теләкләр.
Куш булып туганмы әллә
Безнең юньсез йөрәкләр.
Сәламәтлеккәең булса,
Шат яшәреңне беләм.
Озак яшә, сәламәт бул!
Син авырсаң, мин үләм.

## НИГӘ СОҢ?

Яшь җемелди тургайлар күзендә,
Нурсыз гына карый тонык Ай.
Җилләр елый. Елый үкси-үкси,
Тынычланмый дөнья.
Тапмый җай.
Ярсынулы тургай тавышына
Кушылалар йөрәк моңнарым.
Гел моң булып яшәр идем
Мин дә,
Нигә соң бер тургай булмадым.

## ВӘГЪДӘ, ИРКӘМ

Йөрәгемә хисләр белән яздым,
«Сөям», – дигән назлы сүзеңне.
Вәгъдә, иркәм,
Күңел көзгесендә
Гел күрерсең бары үзеңне.
Аккошлардай тугрылыклы булыйк,
Арабыздан җил дә үтмәсен.
Билгеле бит:
Җирдә бер нинең дә
Мәхәббәткә көче җитмәсе.

## БАР БАЙЛЫГЫМ – КҮҢЕЛЕМ

Гаҗәпләнәм батыр яшьлегемә,
Ул бил бөкте картлык алдында.
Буй-сынымның сылулыгын алды,
Карт имәнгә охшаш бары да...
Ергаланган йөзгә ермалаклар,
Уңган күзләремнең күмере.
Сулган инде яшьлек, гөлләр кебек,
Бар байлыгым – хәзер күңелем.
Ә син картлык,
«Таяк тоттырдым», – дип,
Борыныңны артык күтәрмә.
Картаюны сизмәс күңел барда
Гомер юлын була үтәргә.

## АНА ТЕЛӘГЕ

«Хәләл сөтем хәрәм булыр, – диде, –
Ил йөгенә җигелеп тартмасаң,
Файдасыз җан булып бу дөньяга,
Тутый кош кауры капласаң...»
Аналарның горур, хөр күңеле
Бәхетлеме безнең буыннан?..
Үлем сукмагыннан кабель сөйрәп,
Арып, калтыранды буыннар.
Анам биргән шушы изге үгет
Алга илтте, тотып кулымнан.
Илкәемнең авыр яраларын
Төзәткәндә талса беләгем,
Күңел кылы, дәртле бер җыр итеп,
Кабатлады анам теләген.
Олы юлдан халкым йөге белән
Үткән чакта талса йөрәгем,
Балаларым юлны дәвам итәр,
Гел җитәкләр ана теләге.

## ТАТАР ТЕЛЕ

Яратам мин туган җиремне.
Дөньяны яратам, илемне.
Хисләремне чигәм мин татарча,
Сөямен үз татар телемне.
Бар дөнья белгече җыела...
Бу телдә сөйләми берәү дә.
Аларны аңлыйм мин Мәскәүчә,
Кичерәм гел Казан телендә.
Гетены, Пушкинны яратам,
Укыйм мин аларны русча.
Шулай да татарча әсәргә
Гашыйкмын, мөгаен, үземчә.
Халыклар җырларын яратам,
Биешу җырына әсирмен.
Татарча җырланган һәр җырга
Кушылып җырларга әзермен.
Эшендә калышмас башкадан,
Татарлар масаймас, бик тыйнак.
Теле дә үзенә ошаган,
Бик күркәм, бик саллы, бик җыйнак.

## СӨЮ ХИСЕ

Кирәк чакта су
Һәм икмәк белән
Тигез бүлешәбез,
Бергә кайгырабыз,
Бергә көлешәбез.
Кешегә хас тагын сөю хисе.
Аңа хаклы бары ике кеше.
Аңа дәгъва итсә өченчесе,
Ике ялкын арасына кергән
Күбәләктәй, яна мәҗнүн кеше.
Тик икәүгә хәләл сөю хисе.

## АЮ БАБАЙ ӘРЛӘМӘСМЕ?

Килегез безгә кунакка –
Бездә чыршы бәйрәме.
Җырлап, биеп, шау-гөр килеп,
Әй, уйнарбыз әйләнеп.
Зур урманнан килеп җитте
Аю, бүре, төлкеләр.
Куяннар да курыкмаган,
Юлда икән керпеләр.
Аю бабай әрләмәсме,
Күрсә өлгермәүчене?
Бәхетле тормышыбызның
Кадерен белмәүчене.

## БОЛЫТ ҮТӘ

Күргәнем бар таң йолдызын,
Кара болыт каплаганын,
Чәчәк атасы гөлләрнең
Бозлар сугып тапталганын...
Болыт үтә, Зөһрә тагын
Якты булып яна күктә.
Гөлләр дә бит үсеп китә,
Чәчәк ата, үтми күп тә.

## УПКЫННАР

Килеп җиттем җиде юл чатына.
Төрле уйлар уйный башымда.
Сулда – саздыр. Уңда – кара урман.
Текә кыя капма-каршымда.
Алдымдагы сукмак уртасында
Горур тора биек тау карты.
– Яшәүгә юл әллә тау ашамы?
Карт тау, гүя, шунда баш какты.
Текә тау юлларын кисеп үтеп,
Яшәү яулап йөргән бар безнең.
Ялгыш басып, кыя түбәсеннән
Упкынга очканнар азмыни?!
Ах, упкыннар! Тормыш упкыннары...
Еш тап булды безнең юлларда.
Төпсез упкыннарны тигезләрлек
Чара булса икән кулларда!
Юк, юк!
Монда чара башка һич ни түгел,
Үткер акыл, оста кул кирәк.
Тормыш упкыннарын үтәр өчен
Саф егетләр салган юл кирәк.
Саф егетләр кирәк!
Юл кирәк!

## КЫШКЫ САЛКЫН

Үтә салкын, рәхимсез кыш, димә,
Табигать бу – булыр төрлесе.
Күпме генә узышмасын салкын,
Юк, киметми йөрәк җылысын.
Хезмәт дәрте кеше күңелендә,
Эш агачы яна йөрәктә.
Кеше әзер бүлеп бирергә дә
Салкын кышка ялкын кирәктә.
Кышкы  салкын вакытлыча гына,
Белә ич ул җәйнең киләсен.
Тик күңелдә  җылы кимемәсен,
Дәрт һәм ялкын сүнә күрмәсен.

## КЕШЕ ФАЙДАСЫНА ИССЕННӘР

Ап-ак кардан ак җәймәләр җәйдек
Энҗе белән бизәп өсләрен.
Ел юлында Урал энҗелере,
Җем-җем итә җете төсләре.
И, Яңа ел!
Шундый сафлык китер,
Урал энҗесенә тиң булсын.
Яудыр безгә күктән аклык, пакълек,
Кара мәкер калсын, күмелсен.
Күңелләрдә өмет, йөрәктә дәрт,
Сафлык булса, начар эш булмас.
Безнең яшәү хәзер – яшел чыршы,
Дәртле йөрәкләрдә кыш булмас.
Өметләргә җылы яңгыр китер,
Яшәү көче булып үссеннәр.
Яңа елда жирдә барлык җилләр
Кеше файдасына иссеннәр.

## САУ БУЛ, ӘНКӘЙ!

Ил язмышы – безнең язмыш,
Бирегезче корал кулыма.
Кыз бала, дип, әнкәй, артык көймә,
Изге теләк телә юлыма.
Мин яшемне куеп китәм өйдә,
Нәфрәтемне алам дошманга.
Авылымны, сине саклар өчен,
Яуга китәм акыл кушканга.
Палач килә, илгә әҗәл килә,
Дөньябызны харап итәләр;
Сафны кирәк бүген тыгызларга,
Сау бул, әнкәй, мине көтәләр.

## ТЫНЫЧЛЫК ӨЧЕН!

Ташны уеп языйк имзаны,
Югалмаслык итик без аны;
Мәңге саклансыннар сүзләре,
Жиңгән илнең бармак эзләре.
Онытмыйбыз үткән сугышны,
Әҗәл, төтен буды сулышны;
Саф һавалы зәңгәр күк өчен
Арта барсын тынычлык көче?
Култамгадан корган киртәләр
Гөл бакчасын саклап үтәләр.
Бәхет чәчәк атсын җиремдә!
Корал калсын туган илендә.

## ЧИККӘН КЕБЕК

Шигырь язу – бер тинтәклек,
Буш эш, диләр.
Йөрәктәге нечкә хисләрне
Сизмиләр.
Ефәк җептән умырзая
Чиккән кебек,
Тойгыларны шигырь
Җепләре бизиләр.

## САУ-СӘЛАМӘТ БУЛ

Алтын кояш бүләк итәм сиңа,
Көләч булсын һәрвакыт көнең.
Көмеш аем көлеп торсын күктә,
Адаштыра күрмәсен төнең.
Синең гомереңнең төш вакыты,
Күңел нурларының мул чагы.
Гомер бизәкләре бирсен язмыш,
Яшәүгә ямь өстәсен тагы.
Ана күңеле – бер хыялый дөнья,
Гомер үтә... синнән ни көтә?!
Җил-давыллар ярып яши алсаң,
Сау-сәламәт булсаң, шул җитә.

## ҖИЛЛӘР БУЛЫП ИСӘМ КАЙЧАКТА

Җилләр булып исәм кайчакта,
Күңелемнән гизәм дөньяны;
Тынам кайчак сүнгән учактай,
Таба алмыйм һаман мин аны.
Күңел эзли, күңел юксына,
Сагышларга юктыр һич дәва.
Ярый акылыма буйсына,
Анысы гелән таудай эш таба.
Күңел калса эшкә күмелеп,
Хисләремә тынгы беразга.
Сизә йөрәк күпкә түгелен,
Истән чыгып тора бик азга.
Эш тавының берсен үттеңме,
Йөрәгемә тагын моң тула.
Күңел, мескен, эзләп киттеме,
Төнге йокылар да онытыла.

## ЕЛАДЫМ

*М.Җәлилнең көрәштәше*
*Фәрит Солтанбековка*

Тоткын Фәрит Солтанбеков сөйли:
«Тәндә күпме фашист ярасы!..
Күңелләрдән мәңге китәсе юк
Ул көннәрнең шыксыз карасы.
Тау ярырлык көч бар күкрәктә,
Әйтеп бетмәс үч бар йөрәктә,
Суксаң, сеңдерерлек беләкләр бар –
Чиретеп тә булмый үләткә.
Ни эләксә, шуның белән бирә,
Котырына фашист, ярсына.
Башта давыл улый, чигәдә кан...
Түзү кирәк иде барысына.
Шунда тәүге кабат сабырлыкны
Үтендем мин, ахры, «алла»дан.
Көч һәм үчне авызлыклау кирәк...
Читенлеген шунда аңладым.
Хәлсезләнде козгын. Ташлап чыкты.
Мине камерага яптылар.
Сызланудан бигрәк, гарьләнүдән
Кайнар күз яшьләрем актылар.»

## УРАЛ ТАУГА КҮТӘРЕЛӘ БЕР ИР-ЕГЕТ

Бик зур йөкне җиңел генә
Алып иңгә
Урал тауга күтәрелә
Бер ир-егет.
Ул көз, дими, ул кыш, дими,
Менә һаман,
Йөрәккә дәрт бирсен өчен
Гел җыр җигеп.
Һичбер тозак тота алмас
Хыялларның
Серен белгән каләм очы
Һәрчак кирәк.
Уралымдай сау-сәламәт,
Гомерле бул!
Сүнә белмәс сандал булсын
Шагыйрь йөрәк!

## МӘҢГЕЛЕККӘ ТАБА ҮТТЕ

*РСФСРның атказанган укытучысы*
*Рәфгать Саяповка*

Урамдагы малайларны
Кем соң сөяр?!
«Үс тизрәк, мәктәпкә
Көтәбез», – дияр.
Башларыннан сыйпап,
Назлап үстерер дә,
Эш сөючән, акыллы бер
Кеше итәр.
Ул яраткан кебек, чынлап,
Кем яратыр?!
Кешеләргә якты нурлар
Кем таратыр?
Өметсезлеккә төшмәче,
Көйсез күңел...
Аның уен онытырга
Мөмкин түгел.
Дөрес, кайтмас. Мәңгелеккә
Таба үтте.
Гомерлеккә үзен безгә
Куеп китте.
Бар кешенең күңеленә
Кереп тулган.
Нинди гади!
Нинди бөек кеше булган!
Аның уеның дәвамы –
Шул кешеләр,
Рәфгать бакчасына
Алар су сибәрләр.
Киләчәкнең балаларына ышанып,
Ул үстергән кебек,
Көйләп үстерерләр.

## ЕЛЛАР ЮЛЫ

Килер елның туар көне
Тәрәз чиртә,
Гомеремнең ак бәхетен
Күңел көтә.
Онытылмыйлар кылыч белән
Килгән еллар,
Баш имәде, тезләнмәде
Батыр уллар.
Ул еллар да яши
Тарих гомерендә,
Кайгылы җөй саклый
Җирем күңелендә.
Быел бирсен ак карлы кыш,
Тургайлы яз,
Сандугачка кушылырга
Кулыма саз.
Җир ташысын, моңга күмик
Бу дөньяны,
Мәхәббәткә әсир булсын
Бар ир җаны.
Алтын башак белән тулсын
Илнең кыры,
Дөнья моңына кушылсын
Башак җыры.
Килсен безгә тынгы белмәс
Бәхет елы,
Шатлык өчен ачык булсын
Еллар юлы!

## СИНСЕЗ ЯШӘҮ

Синсез яшәү – гөлсез булыр иде,
Гөл булмаган җәйдә нинди ямь!
Чәчкә елмаймаса, керфек кагып,
Юк, юк! Тормышымда булмый тәм.
Синсез яшәү – иркәм, дәртсез булыр,
Дәрт булмаган төндә нинди көч!
Елгалар да гөрләп акса гына
Эшкә ярый торган була ич.
Синсез яшәү – сүнәр-сүнмәс пыску,
Пыскып торган уттан ни файда!
Ялкынланып янган йөрәк кенә
Нурлар бөркеп тора һәркайда.

## МАШУК

Күтәрелгән давыл, Машук буйлап,
Куерганнар кара болытлар.
Яңгыр койган – җансыз шагыйрь тәнен
Кавказ шулай елап озаткан.
Кавказ күрке булып тора Машук,
Ил сукмагын аскан иңенә.
Лермонтовны алып кочагына
Зур истәлек саклый илемә.
Түм-түгәрәк, горур тора Машук,
Зур кабергә өйгән ком кебек.
Эсседә дә яшел, һәрчак моңлы,
Лермонтов җырлаган җыр кебек.

## КОСМОС КЫЗЫНА

*В.Терешковага.*
*Ул космоста вакытта язылды*

Валя сеңелем, син үтисең бүген
Совет хатыннары теләген.
Җилләр җитеп, тапшыралса әгәр
Зур рәхмәтем – сиңа бүләгем.
Эштән бушап калган минутыңда
Җир егетләренә күз ташла.
Теш агартып, күз кыскалаулары
Күренәме болытлар аша?
Күзлә шуннан тыныч тормыш өчен
Янып торган бер җир батырын.
Кырын карап, хәтта үчекләп оч
Кылыч кайрап яткан матурны.
Эшең беткәч, Валя, өйгә ашык,
Көтәм, күктән алмый күземне,
Килен итеп куя күрмәсеннәр
Йолдыз егетләре үзеңне.

## ЯҢАВЫЛЫМ

Кырларында – алтын башак,
Җир астында – кара алтын,
Ак чәчкәле болыннары
Күңелләремә якын.
Әй, Яңавыл, зур авыл!
Бүә буйда бер авыл.
Үсеп килгән егетләрдәй,
Күтәрелеп килә ул.
Бишәр катлы йортлар тезә
Урамына Яңавыл.
Кешеләргә бәхет бирү
Дәрте белән яна ул.
Әй, Яңавыл – зур авыл!
Бүә буйда бер авыл,
Сылу сынлы кызлар кебек,
Матурлана бара ул.
Кичләрен яшьләр кулында
Сайрый гармун телләре.
Янып эшләү, гөрләп яшәү
Аларның өметләре.
Их, Яңавыл – зур авыл!
Зур шәһәргә тиң авыл.
Тирә-якка сибә моңын,
Якты нурын бирә ул.

## ДОШМАН БОЛЫТЛАР

Тәүлек буе кара болытлар...
Томалыйсыз карар күгемне.
Ишетелә авыр гөрелте,
Сездән өстә дошман түгелме?
Ачылыгыз инде, үтегез!
Фашист самолетын каплыйсыз.
Болытлар – сез дошман күңелдә,
Алар мәнфәгатен яклыйсыз!

## УЗГАН ЧАКТА

Шык-шык итеп, чик-чик итеп,
Таш тия тәрәзәмә.
«Ватасыз бит тәрәзәне,
Кем тия соң мазама».
Баскан да, елмаеп тора
Бер егеткәй каршымда.
«Атна эзләп, чак таптым», – ди,
Тик сөю карашында.
«Очраттым мин сине юлда,
Ошадың күңелемә.
Борылып артыңнан килдем...
Ярым бул гомеремә?»
«Ярым да бар, бар балам да,
Кирәк түгел син миңа.
Юлда әйбәтләр күп булыр,
Пар булмый бит ул сиңа».
Инде менә ничә еллар
Егет эшеннән кайта.
Таш атмаса да, һаман да
Узган чакта күз ата.

## ЗЕМЛЯНКАБЫЗ КАЛЫР

Сүтелмәгән чәчем бер атна,
Үткәргечкә куйган уралып.
Алдагысы бераз ычкынып,
Маңгаема төшкән таралып.
Инде икенче ай юмаган,
Тышта – салкын, өем еракта.
Суыбыз да исәп-хисапта...
Чисталык юк бездә бу чакта.
Сугыш кына бетсен, кайтырбыз,
Землянкалар калыр, алмабыз.
Землянканың юеш идәнен
Тик хәтердән ташлый алмабыз.
Кайтыр әле күңел төбендә
Постта торып үткән бу төннәр.
Бомба төшә, диеп, калтыранып,
Күк күзәтеп үткән бу көннәр.

## ФАШИСТ

Фашистларны без гел ерткыч, дибез,
Кайсы ерткыч шундый эш эшли...
Хайваннарның явыз, иң усалы
Бүген тамак туйсынга яши.
Ерткычлардан усал, ай-яй, явыз.
Күңелемдә сүз юк тиңләргә.
Ул кабәхәтлекнең авырлыгын
Белә күтәргәннәр иңнәрдә.
Яшь баланы штыгына кадап,
Күтәрде ул, күрсен, дип, дөнья.
Бала каны сузылып агып тора,
Төшерәләр фотога шунда.
Фашист үткән җирдә тик көл калды,
Кайтмый калганнарны йотты ул.
Дөнья тарихына  фашист сүзе
Кара чума булып үтте ул.

## СУЛГАН ГӨЛЛӘР

Син үстергән гөлләр үзеңнән соң,
Нидер әйткән кебек булдылар.
Гөлләр телен, ахры, аңламадым...
Никтер алар бик тиз сулдылар.
Җаным тыныч иде, ал гөлләрең
Гел яктыга таба үрләгәндә;
Әллә, әнкәй, син дә сулдыңмы соң
Иркәләү миннән күрмәгәнгә?
Гөлләр белән син сөйләшә идең...
Төсең итеп инде багалмам.
Алтын гөлләр сөеп үстерсәм дә,
Синдәй гөлне мәңге табалмам.

## ДӨНЬЯДАН ЯШЕРЕП СӨЙГӘН ЯР

Еракларга киткәнсең икән,
Мине ялгыз иткәнсең, иркәм.
Дәртем сүнде, яшәү күңелсез,
Көлә белмим икән мин синсез.
Сине эзләп, дөнья гизәрмен,
Син яраткан гөлләр өзәрмен.
Әй, сөйгәнем! Минем өметем,
Сагынуга ничек түзәрмен.
Дөньядан яшереп сөйгән яр,
Үзеңә сиздерми көйгән яр,
Минем өчен генә туган яр,
Сиңа гына әйтер сүзем бар.

## ЙӨРӘГЕМДӘ КАЛДЫ ЭЗЛӘРЕ

Мәхәббәттән шашып, канатланып,
Очып йөрүеңне онытмыйм.
«Сөясеңме?» – дидең, мин оялып,
Янып төшүеңне онытмыйм.
Мин яратып сиңа карап тордым,
Елмайдың син, аңлап күзләрдән.
Ялкынланган чагы сөюемнең,
Көчле иде хисләр сүзләрдән.
Өметләрем бер көн күккә очкач,
Әрнеп, юксынуны онытмыйм.
Яшәү ямьсез, көн күңелсез икән,
Кояш нуры үтмәс болыт мин...

## ҖИЛЛӘР БУЛЫП ИСӘМ КАЙЧАКТА

Җилләр булып исәм кайчакта,
Күңелемнән гизәм дөньяны;
Тынам кайчак сүнгән учактай,
Таба алмыйм һаман мин аны.
Күңел эзли, күңел юксына,
Сагышларга юктыр һич дәва.
Ярый акылыма буйсына,
Анысы гөлән таудай эш таба.
Күңел калса эшкә күмелеп,
Хисләремә тынгы беразга.
Сизә йөрәк күпкә түгелен,
Истән чыгып тора бик азга.
Эш тавының берсен үттеңме,
Йөрәгемә тагын моң тула.
Күңел тагын нәрсә эзлидер,
Төнге йокыларым онытыла.

## ЛАНДЫШЛАР

Ландышлар, әй, гүзәл ландышлар!
Каушадым мәхәббәт хисеннән,
Күңелдә хисләрем уянды
Сезнең саф чәчәкләр исеннән.
Минем дә бик нәфис ак чәчкәм –
Кызчыгым – Альбинам өемдә,
Нәкъ сезнең шикелле, ямь биреп,
Тора ул гел генә күңелдә.
Менә сез, ахрысы, көнләшеп,
Чайкалып куйдыгыз бер якка.
Үзара гәпләшеп алдыгыз,
Шыпылдап колактан колакка.
Киләсе яз килгәч дөньяга,
Сез дә бит яшь ана булырсыз,
Яшь бала ландышлар сезгә дә
Нур булып торганын белерсез.

## ОНЫГЫМ

Әнә, тышта таудан чана шуа,
Аннан кадак кага тактага.
Агачларны тезә, озын итеп,
Күпер салдым, диеп, мактана.
Аңа дүрт тулганда, картәтисе
Утын өйгән чакта кибәргә,
Ул өч шакмак утын алып килгән,
Файдалы эш булган сөйләргә.
Уйнап йөреп кергәч, әйбәт ашый,
Көйсезләнү ягын белми ул.
Минем гаеп: ул – бу эш табылып,
Йокы сәгатенә соңлый ул.
Андый чакта эшләр катлаулана:
– Бака килә, бәбкәм, йокла, – дим.
– Әй, картыем, тими бит ул безгә,
Килсен, әйдә. Син курыкма, – ди.

## УКЫТУЧЫ БУЛГАН УКУЧЫМА

Мин арыдым. Тиздән туктап калам.
Йөкне ал да, юлны дәвам ит.
Киңәш итеп, әйтер сүзем калган,
Күңел дәрьясына маяк ит.
Гомер елгасының саф сулары
Синең бусагаңнан баш ала.
Һәр гомернең чәчәк бөреләре
Синең учта чакта башлана.
Яшь үсенте һәрчак бик тук булсын,
Кысыр чәчкә була күрмәсен.
Җылы кирәк булса, өскә күтәр,
Салкын кирәк, төшер - туңмасын.
Күпне күрдем, минем күз алдыннан
Үтеп торды гүзәл язмышлар...
Сирәк, ләкин һаман булып торды
Безнең эшебездә ялгышлар.
Җавап көтә синнән күп сораулар:
Тау юлының төзен табасы...
Җил, давыллар ярып, иңсәләрдә
Зур йөк белән алдан барасы.
Җавап көтә синнән күп сораулар:
Энҗеләрнең чынын табасы...
Чорыбыздан олы бүләк итеп,
Халкым муенына тагасы.

## ИЛЛЕ БИШ ЕЛ ҮТТЕ

Каракүлдән кара пальто киям,
Пальтом төсле кара бүрегем.
Ә күңелдә, соры шинель киеп,
Сугышка, дип китеп баруым.
Аягымда кара хром итек
Каптырыла торган кырыннан.
Ә хәтердә солдат ботинкасы
Инглизләр биргән, каруннар.
«Каруннар», – дим. Чөнки безнең өчен
Текканнәр бит аны хезмәткә.
Шундый каты. Бөгеп-сыгып булмый,
Лаек түгел алар хөрмәткә .
Ни генә юк минем өстәлемдә,
Аша да эч. Яшә туйганчы!
Истән чыкмый, кружкага салып,
Чәй эчкәнем... Суык, болганчык...
Төнгә керсәм, аста җылы түшәк,
Ефәк юрган ябам өстемә.
Кичәгедәй, арып йоклап алу
Землянкада салам өстендә.
Саз чыгасың...
Әле елга кичәм...
Җир казыйсың, агач кисәсең.
«Куыш булды. Бераз яшим...» – дисәң,
Иртә таңда алга күчәсең.
Җиңү килде!
Илле биш ел үтте!
Уйлаганда, үзе бер гомер,
Чигәләргә үткән авырлыгы,
Хәтерләрдән чыгарлык түгел,
Бәйрәм катыш кайгыларым белән,

Бер елыймын, бер көләм бүген.
Кайтмый калганнарны көтә күңел,
Онытыла торган көн түгел.

## КОЛЛАР ЮК БЕЗДӘ

*Гайбәтчеләргә җавабым*

Игенчеләр икмәк үстерә,
Туйдыра мине һәм илемне.
Ул чәчә, ул ура, ул суга,
Баладай иркәли җиремне.
Укытам игенче баласын,
Өйрәтәм белергә, аңларга.
Балалар утырып эшлиләр,
Мин басып сөйлимен аларга.
Кемне соң кол диеп аңларга?!
Кичләрен театр залында
Утырган бик җайлап һәммәсе.
Сәхнәдә артистлар хезмәттә,
Ачыла гүзәллек пәрдәсе...
Пешекче гел казан кырында,
Эшчеләр станок янында,
Бик теләп башкара үз эшен.
Хезмәттә бәхетле бары да.
Җирдән дә, күктән дә эзләдем,
Эшлеләр күп бездә, коллар – юк.
Эшлене изәргә теләүче,
Буарга торучы куллар юк,
Гаиләбез зур безнең, бик тату,
Җыры да йөзләгән телләрдә...
Тормышның чәчкәсе, орлыгы
Тик хезмәт китергән гөлләрдән.

## БУРЫЧЛЫМЫН

Тагын йөз ел эшләп яшәсәм дә
Бетә торган түгел бурычым.
Сайлап, йөрәк ясап койсалар да
Иң сыйфатлы булат корычын.
Бурычлымын әткәй буынына,
Алар миңа яшәү китерде.
Көн күрмичә киткән булыр идем,
Кояш сөймәс чыклар шикелле.
Җылы җилләр иркәлиләр мине...
Колак төптә әткәй тавышы.
Бик ерак та, бик якын да кебек,
Нигәдер тавышы сагышлы.
«Түлә бурычыңны яшь буынга,
Рәхмәтең җитә атаңа.
Кул көченә яшәр уллар үссә,
Сездән тик шул кирәк Ватанга».

## КАЙТУ

Йөрәгемнең хәле әйбәт түгел.
Көйләр хәл юк, чара тапмыйбыз.
Юллар, юллар! Мине үз ягыма,
Ямьле якка алып кайтыгыз.
Язмышыма каһәр төшсен, әгәр
Мине моннан алып китмәсә.
Бодай үскән иген кырларыма,
Урал якларына илтмәсә.
Анда булыр калын урманнар да,
Тулы сулы озын елгалар.
Сандугачлы яшел болыннары,
Бөркет кунган матур кыялар.
Анда минем эштә үткән гомер,
Анда минем бөтен туганнар...
Азмы җирдә, читтә торып калып,
Аннан-моннан күмеп куйганнар.

## БОРЫЛГАНДА

Бервакытны кайтып киләм
Шулай эштән.
Күңелдә яз... дөнья кадәр
Эшләр башта.
Урам буйлап берәү килә,
Шәп-шәп атлап,
Кулда сумка, үзе яхшы ук
Олы яшьтә.
Борылганда Ломоносов урамына
Чумды кеше көзен чокып
Куйган ямга.
Кулны сузам, имеш, ярдәм
Итәм аңа.
Шуып кына төшеп киттем
Аның янга.
Балчык күле секунд саен
Арта бара.
Ярдәмгә дип кул сузучы
Чумып кала.
Әй, йөзәләр анда-монда
Мескен халык,
Балчык күлен чыга алмый,
Хәйран калып.
Менә берчак кычкыралар,
Сөрән салып:
– Коткарыгыз! Үләбез бит
Аста калып.
Шул чагында өч ир батыр
Килеп житә.
Халык тына. Бер яхшылык
Өмет итә.

Әнвәр батыр мыек очын
Селкетүгә,
Зур йөрәкле машиналар
Йөгерешә.
Закир батыр чәнчәкәен
Болгап куя.
Йөзләгән ир сырып ала,
Башлый эшкә.
Шакир батыр әмер бирде
Корытырга.
Чокырдагы бар балчыкны
Суыртырга.
Җиң сызганып, корал алып
Чыккан бар да,
Әбиләр дә, бабайлар да,
Балалар да.
Ни күзләре белән күрсен
Чокыр кипте...
Асфальтланган... Чәчкәләре
Үсеп китте.
Өч батырга, рәхмәт әйтеп,
Баш иделәр.
Юлларына чәчәк бәйләме
Куйдылар.
Кешеләрнең өс-баш чиста,
Күңеле шат.
Урам буйлап горур барам
Киереп түш.
Чек-чек басып рәхәтләнеп
Барган чакта,
Уян да кит... Булган икән,
Каһәр, бу – төш!

## КҮҢЕЛДӘ ЧЫН СӨЮ БУЛГАНДА

Күк көн дә зәп-зәңгәр була ул,
Җаныңа сайрар кош куна ул,
Син мине: «Кадерлем...» дигәнгә,
Мин сине өзелеп сөйгәнгә.
Тулган ай гел көлеп карый шул,
Күңелдә тургайлар сайрый шул,
Мин сине: «Батырым», – дигәнгә,
Син мине: «Матурым», – дигәнгә.
Кич тула күңелгә зәңгәр моң,
Таң бирә көннәргә алсу нур,
Йөрәктә чын сөю булганда,
Яшәү гел сагышлы шатлык ул.

## ДӘРЕС МИНУТЛАРЫ

Уку елы дигән ел башлана.
Яңа елга изге теләкләр.
Белем йорты зур көч сорый,
Талмасыннар сезнең йөрәкләр.
Мәктәпләргә таба атлый бүген
Җирне ал-гөл итәр кешеләр.
Хыяллары космос киңлегендә,
Әкияттәге батыр ишеләр.
Өнди укытучы чынбарлыкка,
Күңелләргә ачкыч ярата.
Ничә төрле белгеч үз көенә,
Моң бирерлек итеп, кыл тарта.
Җиде яшьтән унҗидегә кадәр
Кушылырга заман җырына.
Әзерли ул безнең балаларны
Тап төшермәсен, дип, чорына.
Хәерле юл, белем бирүчеләр!

## ӘЙТ, ҖАНЫМ?

Исән бул, егетем, исән бул!
Язмышлар шулайдыр – аерылдык.
Аралар бик ерак түгел дә,
Баралмам, канатлар каерылды.
Йөрәкнең җылысы сүрелмәс,
Сагынган чагыңда искә ал.
Давыллар котырып торса да,
Син һаман мин әйткән юлдан бар.
Эчәргә өйрәнеп киттең бит,
Теләдем айрырга «шешәдән».
Син мине яманлап хурладың.
Имеш, мин, матур яр, «пешмәгән».
Әйе... Син үкендең, айныгач...
Саклачы башыңны «шешәдән».
Син әле килерсең – мин көтәм.
Ничәнче сүз бирдең: «Ташлыймын».
Мин хәзер ул сүздән пешәмен,
Бер янам, бер суга төшәмен.
Шешәне җиңалмый, җиңелсәң,
Әйт, җаным, мин шунда
Нишләрмен?

## АЗДЫР ИЧ

Ап-ак кышлы, яшел җәйле җирем,
Нинди тылсым синең көчеңдә!
Күпме тойгы, күпме җылы хисләр
Биргәнсең бит һәрбер кешегә.
Һәр чишмәнең үзенә хас тәме,
Чәчкәләрнең үзенчә төсе...
Бетмәс гүзәл байлыгыңнан, җирем,
Өлеш алып яши бар кеше.
Бер тиен дә хак түләми генә
Кояшыңнан алтын нур алдым.
Җырчы кошларыңнан гомер буе
Күңелем тулганчы моң алдым.
Зифа каен,
Батыр имәнеңнән,
Кара туфрагыңнан алдым көч.
Бирмәгәнмен икән,
Бер нәрсә дә...
Туфрак булу гына
Аздыр ич?!

## КҮРӘ БЕЛМИ ДӨНЬЯНЫҢ ЯМЕН

Дәһшәт ялкыныннан көлгә калып,
Буп-буш калган җирләр хәтердә...
Әйтерсең лә, җирдә урын җитми,
Сугышалар... сугыш хәзер дә.
Нигә сугышалар? Юк, тикшермим,
Бер тиен дә тормый ул миңа.
Кайгы тулы кара табут кайтты...
Бу һәлакәт кемнән соң, нигә?!
Мин үземчә аңлыйм сугыш хәлен,
Кемдер тели һаман кан тәмен.
Кешеләрчә яши белми җирдә,
Күрә белми дөньяның ямен.
Һәр иртәдә алсу таң атканда,
Һәр йөрәккә кага җылы җил.
Мәхәббәттә сүнмәс ут кабына,
Менә шуны, кеше, шуны бел!

## МОРҖАЛАР

Авыл янган фашист утыннан,
Бар байлыкны талап алганнар.
Тик морҗалар тора кирпечтән.
Алар гына басып калганнар.
Кот очарлык булыр иде, әгәр
Үлгән солдат калса шушылай.
Морҗалар да җанга кызганыч,
Мөмкин язуың да һушыңнан.
Ярый солдат яна ут эчендә,
Басып калмый үлгән чагында;
Кискән имән кебек, ятып кала
Үзе туган жир кочагында.

## ӨР-ЯҢА ЮЛ ЯРЫП КИЛ, ЯҢА ЕЛ!

Өр-яңа юл ярып кил, Яңа ел,
Иске елда – мәкер өеме.
Гөнаһ тавы тора иске юлда...
Юлдан язган халык өере.
Өр-яңа юл ярып кил, Яңа ел,
Юлың якты, җылы, ак булсын,
Шушы юлдан үтәр кешеләрнең
Күңелләре кардай саф булсын.
Өр-яңа юл салып кил, Яңа ел,
Юлың ямьле, җырлы юл булсын.
Кайгылардан каткан күңелләрне
Эретердәй җылы ел булсын.
Җырыма моң, сөйгәнгә яр китер,
Мәхәббәт булмаса, нинди ямь?!
Сөю белән дәртле, көчле кеше,
Янып яшәвеннән таба тәм.
Яңа йолдыз алып кил, Яңа ел!
Йөрәкләргә якты нур тулсын.
Бәхет китер безгә,
Тик бер бәхет!
Синең бүләк бары шул булсын.

# ҖИЛЛӘР ҖЫРЫ

Исеңдәме, шау чәчәкле,
Хуш исле, ямьле болын.
Кыр чәчәкләре каплады
Без йөргән болын юлын.
Шәфәкъ бата, ай калыка,
Чыгам синең сукмакка.
Синең җырны көйли җилләр,
Юксындыра шул чакта.
Җилләр җыры, кошлар моңы –
Синең сагышлы тавыш...
Тап юлларын, кил яныма,
Саргайтмас борын сагыш.

## САЙРЫЙ ТОРГАН КОШЛАР КАЙТЫР

Менә инде НАТОлылар «эшкә башлый»:
Юк-бар сәбәп тапкан булып, бомба ташлый.
Ниләр җитми бу дөньяда кешеләргә?
Юк-юк! Әле безгә түгел, күршеләргә.
«Күрше хакы – Алла хакы», – дияр урыс,
Күршеләрне яклау, имеш, безнең бурыч.
Күрше яклап сугышырдай заман түгел.
Бу сугышка катнашырга каршы күңел.
Телевизор экраннарын, әнә, кара.
Ике төрле фикер өчен сугыш бара.
Юләрләрне сайлап куйдык бит үзебез,
Тилелекләрен күрәбез, юк сүзебез.
Сугыштан соң үсеп җиткән асыл ирләр,
Гарипләнеп, кайтып тулыр тагын илгә...
Сугыш – әҗәл, сугыш – ачлык, сугыш – газап.
Башласагыз, үкенерсез бит, сез, азак.
Сугыш башлаган адәмнәр, сез дә – кеше.
Кешелекне җимерергә җитмәс көчең.
Үчең булса, телең белән генә аңлат.
Корал тотма, җимерәм, дип, инде кабат.
Бу дөньяның матурлыгын сизеп яшик.
Кимчелек күп. Белеп торам, түзик, дәшмик.
...Озакламый сайрый торган кошлар кайтыр,
Җир яшәрер, төрле-төрле чәчәк атар.

## БӘХЕТ КИТЕР БЕЗГӘ, ЯҢА ЕЛ!
### (пьеса)

Катнашалар:
Әтәч.
Эт.
Куян.
Бүре.
Аю.
Кыш бабай.
Гармунчы малай.
Гөлчәчәк.
Назлыгөл.
Биюче кыз.
Яңа ел киемендәге малай.
Хәрби киемдәге ике малай.
1 нче солдат.
2 нче солдат.

Яңа елны каршы алыр өчен бизәлгән зал. Уртада матур уенчыклар белән бизәлгән чыршы утыра. Стена буйларында утыргычлар. Хайваннар ролен башкарган балалар битлек (маска) кигәннәр, койрык такканнар. Әтәч белән эт сәхнәнең икесе ике ягыннан чыгалар. Сәхнә уртасында очрашалар.

Эт: Ау-ау! Кая барасың, сырлы кикрик?

Әтәч: Кик-ри-күк! Яңа елны каршыларга барам, Алабай.

Эт: Ау-ау! Яңа ел белән тизрәк очрашасың килсә, ул якка барма.

Әтәч: Кая таба барырга соң?

Эт (көнчыгыш якка күрсәтә): Бу якка бар. Әй, онытып торам икән. Сезнең халык кичкә таба күрми башлый бит.

Әтәч: Ә син нишләп йөрисең, Алабай?

Эт: Мин дә Яңа елны каршыларга чыктым.

Әтәч: Алай булса, бергә барыйк.

Эт: Мин кешеләрне көтәм әле. (Утыргычка барып утыра).

Әтәч: Мин дә кешеләрне көтим. (Ул да барып утыра. Сөйләнә-сөйләнә исерек куян керә).

Куян: Их! Кичә дә кичә! Тып-тын гына.

Җилсез генә... Их!

(Җырлый.)

Яңа елда кибетләрдә

Аракы күп булса иде.

Агыйделкәй спирт булып,

Күктән пилмән яуса иде.

Их!..

Эт: Ау-ау! Шаулама, кыска койрык! Яңа елга исерекләрне кертмиләр икән дигән сүзне ишетмәдеңмени?

Куян: Юк! Ишетмәдем!

Ишетергә дә теләмим.

Эт: Ау-ау! Без кешеләрне көтәбез. Син дә тын гына утырып көт, кыска койрык.

Куян: Утырам. Нигә утырмаска. Курыкмыйм мин синнән. Утырам. (Утыра.)

Гармун тоткан малай белән Кыш бабай керә.

Кыш бабай: Күр әле! Яшел чыршы нинди матур итеп бизәлгән! Яңа елны көтә. Без дә аның янында көтик әле Яңа елны.

Малай: Монда соклангыч матурлык. Шушында көтик. Бездән алданрак килүчеләр дә бар икән. Саумысез, чибәркәйләр! (Этнең башыннан сыйпап.)

Эт: Ау-ау!

Әтәч: Ки-ки-ри-күк!

Куян (бик нечкә тавыш белән): Саумысез, Кыш бабай!

Кыш бабай: Саумысез, барыгыз да! (Гармунчы малайга.)

Я әле, улым, уйнап җибәр гармуныңны! Бәйрәм ямьле булсын.

Малай: Була ул, Кыш бабай. Хәзер...

(Үзе уйнап, үзе җырлый.)

Гармун телләре сайрыйдыр
Бәйрәм ямьле үтәр дип.
Иске елны озатабыз,
Ул кайтмаска китә бит.

Кыш бабай: Дөрес. Кайтмаска китә шул.

(Гөлчәчәк белән Назлыгөл керәләр. Алар артык кыска юбка кигәннәр.)

Гөлчәчәк, Назлыгөл (тыйнак кына): Саумысез, Кыш бабай!

Кыш бабай: Саумысез, балалар. Сез кая юл тоттыгыз?

Гөлчәчәк: Без Яңа елны каршыларга чыктык.

Кыш бабай (юбкаларына ишарәләп): Шулаймы?

Ярамый, балалар. Кызларга мондый кыска киемне кояшта кызынганда гына кияргә ярыйдыр. Кеше күрмәгән урында гына... Яңа ел сезгә карарга оялыр бит.

Назлыгөл: Алай булса, без хәзер... (Артка борылып, яшереп, күтәрелгән итәкләрен төшерәләр.)

Кыш бабай: Менә бит, нинди матур булдыгыз! Инде Яңа елны каршылау кичәсендә нинди һөнәр күрсәтергә телисез?

Гөлчәчәк: Без җырлый беләбез.

Кыш бабай: Бик әйбәт.

Җырыгызны тыңлап карыйк.

Гөлчәчәк (җырлый):

Толпар килә атлап-атлап,
Энҗе карларны таптап,
Карлар булып явар идем,
Булса дөньяны пакълап.

Кыш бабай: Рәхмәт, кызым. Булыр дөньяны пакълап. Булырга тиеш. (Назлыгөлгә.) Инде син җырла, матуркай!

Назлыгөл (җырлый):

Күңел көлә,
Күңел көлә челтәр карлар
Керфекләремә кунса.
Бөртек кардай эрер идем,
Җирдә тынычлык булса.

Кыш бабай: Матур җырлыйсыз, кызлар. Рәхмәт, сезгә! Гел шатлыклы җырлар җырлап үтсен гомерегез Яңа елда.

Аю керә.

Аю: У-у-у-у! Хәерле кич! (Ишек төбендә тора.)

Кыш бабай: Хәерле булсын берүк. Әйдә, ялкау, ишек төбендә торма! Түргә уз! Йокыңнан айнып килүеңә рәхмәт.

Аю: У-у-у-у! Бәйрәм бит.

Кыш бабай: Бәйрәм шатлыгыннан бер биеп ал әле, ялкау. Сезнең нәселне биергә оста, диләр бит.

Аю: Анысы булыр. (Аю бик авыр итеп, әкрен генә биеп китә. Сәхнәдәгеләр кул чабып торалар. Бераздан Аю биегән көйгә, бию хәрәкәтләре ясап, милли кием кигән биюче кыз чыга. Аны күргәч аю туктап карап тора да, утыргычка барып утыра. Гармун җиңел бию көе уйный. Кыз милли бию башкара. (Татар яки башкорт биюе күз уңында тотыла.)

Кыш бабай: Рәхмәт, балакай. Яңа елда да шатланып, биеп үтсен гомерең.

(Бүре керә. Куян куркып сикереп тора да эт артына яшеренеп, посып утыра.)

Эт: Ау-ау! Рәхит ит, бүре дус!

Бүре: У-у-у! Яңа ел барыгызга да дуслык китерсен.

Кыш бабай: Изге теләгең өчен рәхмәт. Барыбыз да бер Кояш астында яшибез. Дуслык булса гына яшәү бәхетле була. Дуслык бик кирәк, бүре дус. Без монда Яңа елны каршыларга җыелганбыз. Кем нинди һөнәр күрсәтә ала, шуны да карыйбыз. Бүре дә үз һөнәрен күрсәтер, дип уйлыйбыз.

Бүре (аптырап): Мин ни... ни... (Башын ике аягы арасына куеп, тәгәрәп китә. Һәммәсе дә көләләр, кул чабалар.)

Кыш бабай: Рәхмәт. Белгән – белгәнен эшли, белмәгән - беләген тешли, диләр бит. (Хәрби киемдә ике солдат малай керә. Алар коралсызлар.)

Солдатлар: Честь бирәбез, Кыш бабай! (Уң кулларын баш киеменә куеп.)

Кыш бабай: Сәламәтлек телим. Менә солдатлар да килделәр. Коралларыгызны күрмим, солдатлар.

Беренче солдат: Без коралларны ташладык, Кыш бабай.

Икенче солдат: Хәзер тынычлыкны корал белән саклап булмый, хөрмәтлебез.

Кыш бабай: Алай икән... Ә ничек сакларга уйлыйсыз тынычлыкны?

Беренче солдат: Тынычлыкны саклар өчен акыл кирәк.

Икенче солдат: Без яңа елдан акыл сорарга килдек.

Беренче солдат: Әйе, акыл сорарга килдек, Кыш бабай.

Кыш бабай: Сугыш коралын ташларга акылыгыз җиткән. Рәхмәт, солдатлар. Тынычлыкны акыл белән ничек сакларга кирәген дә табарсыз кебек күренә.

Әйе, Яңа ел ярдәм итәр, Ходай кушса.

Солдатлар: Амин!

Ярдәм итә күрсен иде инде, Кыш бабай!

Кыш бабай: Теләгебезне Аллаһу Тәгалә ишетер. Өметебезне сүндермик. Без монда Яңа ел җиткәнче һөнәрләребезне барлыйбыз. Солдатлар да буш кул белән килмәгәннәрдер.

Беренче солдат: Мин шигырь сөйли беләм.

Икенче солдат: Мин дә.

(Сәхнә артыннан кыңгырау чыңы, ат тояклары тавышы ишетелә.)

Кыш бабай: Ишетәсезме! Бу – ул. Яңа ел килә. Мин каршыларга чыгыйм. Ә сез, кадерле солдатлар, шигырь сөйли торыгыз.

(Кыш бабай чыгып китә.)

Беренче солдат (шигырь сөйли):

Ак җәймәләр җәйдем ап-ак кардан,
Энҗе белән бизәп өсләрен.
Ел юлында Урал энҗеләре
Җем-җем итә җете төсләре.
И, Яңа ел!
Шундый сафлык китер,
Урал энҗесенә тиң булсын,
Ак бәхетләр булып яусын карлар,
Явызлыклар калсын, күмелсен.
(Алкышлыйлар.)
Икенче солдат:
Яңа елым!
Безгә акыл китер!
Һәммәбезгә булсын җитәрлек.
Акылсызлар явын юл яздырып,
Яшәү йөген төяп үтәрлек.
(Кул чабалар. Пауза. Һәммәсенең күзе ишектә.)
Барысы бергә: Яңа ел килә!
Солдатлар: Рәхим ит, Яңа ел!
(Иңбашына 5-6 яшьлек малай – Яңа елны утыртып Кыш бабай керә. Сәхнәдәгеләр алкышлыйлар.
Яңа ел кулын өскә күтәреп: Мин сезгә бүләккә һәммәгезгә җитәрлек олы бәхет алып килдем.
Балалар: Рәхмәт, Яңа ел!
(Алкышлыйлар).
Пәрдә төшә.

## ЕГЕТ ЕГЕТЛЕГЕН ИТӘ
### (поэма)

Болыннарның шау чәчәктә чагы,
Дулкыннар уйната кыр ягы.
Җәйге кояш алтын нурлар суза,
Елгаларда серле моң ага.
Ах, ни булды!
Давыл күтәрелде,
Чайкалалар гөлләр болында.
Тып-тын яткан күлдә дулкын ярсый,
Кара болыт нурлар юлында.
Җәһәннәмме әллә?..
Кот очарлык!.
Үлем килә, яшәү чигенә.
Кара кайгы булып сугыш килә,
Әҗәл куеп бомба эченә.
Чик буеннан ерак түгел иде
Майор хезмәт иткән гарнизон.
Сәгать биштән бар да хәрәкәттә,
Корт оясы кебек пыр тузган,
Ашыгулар, йөгерешү анда...
Кара төтен буа сулышны.
Дошман явын кайдан каршыларга?..
Көтмәгәннәр иде сугышны.
Кырып, таптап килә явыз фашист,
Талап бара бөтен барлыкны.
Иген үскән кырлар юкка чыга,
Һәлак итә күпме халыкны.
Канәгатьлек сизгән иде майор
Дошман самолетын яндырып.
Бомба ярчыгыннан корбан булды,
Сережасын ятим калдырып.

Халыкларны тылга озаталар.
Кабалану... елаш... сүгенү...
Сережасын җитәкләгән ана
Китмәскә уйлады бүген үк.
Тагын козгын күренде офыкта,
Машиналар китте кузгалып.
«Әйдә, улым, атаң каберенә», –
Диде ана, уңга күз салып.
Килә ерткыч... Менә бомба ява.
Җиргә сыендылар, кот очып.
Солдат булган җирне «сыйлады» да,
Китте кайтып, кирегә очып.
Баш калкытты Сергей,
Торып басты,
Анасына күзен төшерде.
Ярчык тишеп кергән чигәсеннән...
Ана тормас. Малай төшенде.
Майор Алексеев улы Сергей
Торып калды ата-анасыз.
Өзгәләнеп, үксеп түккән яшь тә
Юа алмый йөрәк ярасын.
Каберлектән әтисенең дусы
Ваня абый белән кайтты ул.
Хатын, балалары тылга китте...
Туенырга нидер тапты ул.
Икенче көн тылга озатырга
Хат та язды, тапты машина...
Ун яшендә бала олыгая, дип,
Килми иде аның башына.
Балалар йортына озатырга
Күрмәде ул нинди чаралар!..
Я йөгерә малай, качып кала,
Бар чаралар бушка калалар.

Менә беркөн таң беленер чакта,
Эзләп чыкты майор малаен.
Атасы каберен кочаклаган,
Йоклап киткән икән малае.
Шул көннән соң вәгъдәләште алар,
Бер-берсеннән аерылмаска.
Бергә эшләп, бергә газап чигеп,
Бер адым да арттан калмаска.
Бергә чигенүләр... очрашулар...
Якын көнгә план корулар.
Кайда булса, шунда тамак ялгап,
Төрле җирдә куныл йөрүләр.
Көннәр үткән саен, әҗәл белән
Якыная бара аралар.
Кайгы йөге төяп килгән көннәр,
Хәсрәт өеп, китеп баралар.

Иван Михайлович олы яшьтә,
Мөхәррире иде гәзитнең.
Арттан торып һөҗүм итәр өчен,
Җаен белеп эшли һәр эшне.
Партизаннар отряды туды.
Отрядта башлык – ул – «Бабай»,
Монда һичкем эшсез түгел иде,
Олылар да, хәтта өч малай.
Сережага эш йөкләтте Бабай
Олы юлда исәп алырга,
Йөкле машиналар Дубовойга
Ничәү үтә, санап барырга.
Бүген машиналар күпләп үтә,
Өлгер генә санап торырга.
Менә агылулар азаялар,
Кояш кичкә таба борыла.

Елга буйлап йөгерә-атлый
Сергей кайтып җитсә, ни эш? Ни күрсен!
Землянкалар буп-буш торып калган,
Эзләп тә тапмады һичберсен.
Аш пешергән җирдә тәртипсезлек,
Идәннәрен чүпләп беткәннәр.
Сережага зур бер бөтен икмәк,
Бер бәрәңге куеп киткәннәр.
Колаклары эләктереп алды,
Бик еракта этләр тавышы...
Качып барган чакта күреп алды,
Үлеп яткан якын танышын.
Бераз барса үлгән фашист ята.
Аның автоматын чәлдереп,
Кача-поса табан ялтыратты,
Үлекләрне төнгә калдырып.
«Фашистларның берсе исәндер дә,
Монда кемнәр яши – белгәндер,
Эт этлеген итеп, отрядка
Эт өере белән килгәндер, –
Дип уйлады Сергей, – күчеп китү
Эз югалту өчен булгандыр».

Кара бәрхет бөркәнгән бу төн дә
Үтәр өчен килгән дөньяга.
Төн карасын ертып, таң сызыла,
Алсуланып килә көньягы.
Күзәтүче бер кыз постта тора,
Гаҗәпләнеп серле тынлыкка.
Уйларында аяз кояшлы көн,
Өметләре – бәхет, муллыкка.
Хыялында дөнья гизгән чакта,
Шәүлә күреп калды каршында.

Ул, сагаеп, карабинын тотты,
Әлләниләр үтте башыннан.
– Курыкмагыз, зинһар, курыкмагыз! –
Диде шулчак бала тавышы.
«Бала бит бу» – дип уйлады сакчы, –
Килеп чыккандыр ул адашып".
– Теге куаклыкта төн үткәрдем,
Бик өшедем, кертмәссезме?
– Юк, балакай, анда ял итәләр,
Кочагымда җылытам сине.
Ымлап чакырды да үз янына,
Автоматын кушты салырга.
Җылы куен бик тиз әзерләнде,
Аркасыннан кочып алырга.
Җәй азагы. Төнге җилләр инде
Бу якта да кыюланалар.
Бер кат күлмәк кигән малайларның
Тәннәренә юлны табалар.
– Нигә пышылдыйбыз? Фашистлар бит
Өченче көн китеп беттеләр, –
Диде малай, күп белдекле булып,
Авылны яндырып киттеләр.
– Кичтән китсә дошман, иртән килә...
Бәлки, килмәс өчен китмәгән...
«Саклаганны гына саклармын», – дип,
Аллаһыбыз белми әйтмәгән.
Пыш-пыш килеп, байтак серләштеләр.
Исемнәрен әйтеп сөйләшү.
Сережаның әти-әниләре...
Кызганулар... кайгы бүлешү.
Житте постның алмашынып чагы,
Басты бүтән, тынсыз-тавышсыз.
Юеш землянкага керде Сергей,

Монда инде җилсез-давылсыз.
– Тсс! Сөйләшмә.
Өенчебез ялда.
Аптырады Сергей шул чакта...
Мәрьям аны тагын арттан кочып,
Җайлап ятты салам түшәккә.
Яраттылар кызлар Серёжаны,
Күзләрендә очкын, нуры бар.
Ятим калган, уйчан бу балада
Тын тормышның серле моңы бар.
Командирлар: «Детдом!» – дигән саен,
Мәрьям итәгенә тотынды.
«Харап булырсың!» – дип куган саен,
Мәрьям ярдәмендә «котылды».
– Минем улым булырсыңмы, Сергей?
Улым булсаң, бирмәм һичкемгә.
– Сүзең чынлап булса, әнкәем бул?
Кирәк түгел башка беркем дә.
Муеныннан кысып кочаклады,
Мәрьямнең ул үпте битләрен.
Ни кушылса, шуны эшләп йөрде,
Бер адым да читкә китмәде.
– Туган телем – татар теле, Сергей,
Улым белсен минем телемне!
– Өйрәт мине, әнкәй? Өйрәт кенә,
Беләчәкмен синең телеңне.
Күзәтү пункты еш күчерелә,
Мәшәкатьләр монда җитәрлек.
Кызларга ул шулай ярдәм итә!
Карап торсаң, исең китәрлек.
Авыр хезмәт тулы шул көннәрдә
Көн дә ун сүз ятлый күңелгә.
Матур татар теле энҗеләре
Байлык булсын, диде, гомергә.

Озак йөргән... тапкан!
Хат! Хат килде!
Фото да бар конверт эчендә.
Менә шатлык! Сергей күргән иде
Ак күгәрчен бүген төшендә.
Ак яулыгын түбәсенә чөйгән...
Шундый моңсу аның күзләре.
Мәрьям күңелендә яңгырады:
«Исән кайтчы!» – дигән сүзләре.
– Бу – картыең. Сылубикә була.
Ә бу – сеңлем. Зифа исемле.
Ни диярсең, Сергей, картыкаең
Сәлим, дигән синең исемне.
Менә укып кара, аңларсыңмы?
«Сирәк килә, – дигән, – хатыгыз.
Сәлимемне куеп, ятим итмә.
Сугыш беткәч, бергә кайтыгыз».
И, шатланды Сергей! И, шатланды
Картыйсының җылы сүзенә!
Торган саен карап-карап алды
Матур йөзле Зифа күзенә.
Көннәр үткәч, Сергей ни уйлаптыр,
Сорап алды хатны, фотоны.
Бик кадерләп кәсәсенә салды,
Аннан... адресын ятлады.
Хат килгәннән бирле Сережаның
Күтәрелде бераз күңеле.
Чәй кайнаткан чакта, кычкырмыйча,
«Каз канаты» җырын көйләде.
«Каз канаты кат-кат була,
Ир канаты ат була.
Чит илләрдә йөргән чакта
Бик сагынган чак була...»

Җырның сүзен дөрес әйтүенә
Мәрьям бик сокланып тыңлады,
Көйнең нәфислеге бозылса да,
Бер сүздә дә хата булмады.

Мәхшәр бүген.
Мәрьям күзәтүдә.
Өлгер... Өлгер хәлне билгеләп.
Тезелешеп, өч-дүрт козгын килә,
Белдерергә кирәк тиз генә.
Менә берсе үтә уң ягыннан,
Икенчесе түбә өстеннән...
Зенитчылар уты киртә була,
Алга үтми, бомба төшерә.
Актарыла таш, кан. Зыңлый колак.
Дөнья бетә кебек тоела.
Мондый ерткычлыкны картлач Җирем
Күрмәгәндер гомер буена.
Һәр башланган эшнең азагы бар...
Бу давылга тынар чак җитте
Барын кырды.
Җимерелде җиркәй...
Күпме кешеләрне юк итте.
Күрче!
Мәрьям ята... чалкан төшкән.
Шомырт кара күзләр ачылган.
Зифа сыны күкрәгенә кадәр
Авыр балчык белән басылган.
Сережаны тотып тыеп булмый,
Ярсып елый, балчык актарып,
Аякларын җирдән чокып алды...
Битен биткә терәп саклады...
Каберен кочаклап, төн чыкты да,

Командирны эзләп атлады.
Озаттылар аны ерак тылга,
Юлдаш булыр кеше тапмады.
Килеп иртә Казан вокзалына,
Аяк басты татар җиренә.
Иңнәрендә авыр кайгы йөге,
Каршылады язгы җил генә.
Эзләп-сорап килеп җитә малай
Мәрьям туып-үскән авылга.
Соклана ул горур агып яткан
Иделкәйгә, яшел болынга.
Менә тапты дүртпочмаклы йортны,
Өй артында шомырт агачы...
«Мәрьям кайтмас», – диеп, ничек кенә,
Ничек кенә ишек кагасы?!
Бераз уйга батып торганнан соң,
Ачып керде капка келәсен.
Бу йорт әле белми иде. Юк, юк!
Нинди авыр хәбәр киләсен.
Ихатада ак күлмәкле Зифа.
– Исәнмесез, Зифа! Мин – Сәлим.
Йөгерде ул. Өйгә кереп китте,
Сорамады Сәлимнең хәлен.
Сылубикә чыкты. Ул, елмаеп,
Каршы алды Мәрьям малаен.
– Йөри торгач, төшендеңме, улым,
Сугыш бала эше булмавын?..
– Горе алып килдем сезнең өчен.
– Нәрсә алып килдең? Аңламыйм.
– Мәрьям әнкәй үлде... Ул күмелде.
Җентекләп сөйләрмен калганын.
Пычак белән кадагандай булды,
Чәнчеп алды ана йөрәге.

Авыр кайгы басты. Чүгәләде.
Табылмады сүзнең кирәге.
Калтыранган тәнен җиңә алмый,
Көне буе ятты түшәктә.
Зифа белән Сәлим аның янда,
Түзәргә өндиләр ничек тә.

Килер көнгә кайгы киртә түгел,
Көн артыннан үтеп тора көн.
Шәфәкъ бата, кара шәл бөркәнеп,
Уйлар булып килә айсыз төн.
Өй янында бакча җире бик зур,
Сылубикә чәчкән барын да.
Эшли Сәлим, эшли. Утый, күмә...
Һичкем ишетмәде зарын да.
Менә печән җитте. Ул болында.
Зур булмаган чалгы кулында.
Зифа аш китерә көн дә, көн дә,
Киртәләр юк аның юлында.
Сылубикә кул арбасы белән
Йортка ташый Сәлим чапканны.
Малай биргән өчен язмышына
Рәхмәтләр укып шатланды.
Менә тагын килде арба сөйрәп,
Ашарга да үзе китерде.
Буы чыгып тора бәрәңгенең,
Әле генә пешкән шикелле.
Йомырканы әрчи башлады да:
– Ә сезгә? – дип, сорау ташлады.
– Борчылмачы, улым. Без дә өйдә
Үз өлешебезне ашадык.
Өч тавыкка бүген бер йомырка,
Пешереп китерде Сәлимгә.

«Үсмер бала. Эше җиңел түгел,
Керергә кирәк, – дип, – хәленә.
Шулай, балам, үзең тырышмасаң,
Кем көйләсен синең көеңне...
Әгәр умач көн дә сөттә пешсә,
Ачлык читләп үтәр өемне.
Чокыр-чакыр җирдән чаба торгач,
Күпме печән! Исең китәрлек.
Кәҗә бәрәнен дә калдырырбыз.
Быел ике башка җитәрлек».
Чи печәнне арбасына төяп,
Китте тартып авылга таба.
Сәлим, бераз ял итмәкче булып,
Ятты чалкан, һавага карап.
Сережага яшәү җиңел түгел,
Һәркем өчен хәзер михнәтле...
Ялгыз калган саен җаны сызлый,
Хәтерли ул бәхетле чакны.
Онытылмый, назлап, сары чәчле
Фаина мамасы сөйгәне...
Урамда сугышып, елап кергәч,
Аның өчен ничек көйгәне...
Җыр өйрәтә иде сөйгән ата,
Яр буенда комда ятканда.
Тып-тын гына җырлап утыралар,
Күл буенда балык тотканда.
Исенә төшерде шаян җырны...
Җырлады да, калды моңаеп.
Ничек кенә тапсын яшәү җаен!
Бу тормышның кайда уңае?..
Ах, сез! Хәтердәге матур көннәр!..
Чалгысын алды ул кулына.
Кояш әле югарыдан көлә,
Эшли. Чыкмый кайтыр юлына.

Шушы көздә татар мәктәбенә
Аяк басты Сәлим укырга.
Телне әле яхшы белмәсә дә,
Барысын да аңлап утыра.
Ел артыннан еллар килеп тора,
Сугыш сүнде. Ачлык үтмәде.
Бөтен теләк – тик бер телем икмәк...
Икмәк?
Күз алдыннан китмәде.
«Ачыкмаска чара», – диде Сәлим,
Ясарга өйрәнде чабата.
Бер киемгә өч стакан он бит...
Үлем түгел... Яшәү ләбаса.

Нинди матур булып үсеп килә,
Тәмамлады җиде классны.
Картыеның ай-ваена куймый,
Дөнья йөген үзенә асты.
Сокланыплар туймый Сылубикә,
Кызы матур, уңган малае.
Зифа, Сәлим кышлык утын ташый,
Серләшәләр табып бер җаен.
Икесе дә эшчән, икесе дә...
Зифа тик бер яшькә кечерәк.
«Зифакаем, сине яратам», – дип,
Ничек әйтсен икән..» Ничекләр?!
Ана күңеле сизми буламы соң!
Шикләнеп, кисәтте Зифаны.
Сер яшерә белми япь-яшь бала:
– Әнкәй, яратам бит мин аны.
– Рәхмәт, кызым. Яратырга ярый.
Иртә якынайтма араны.
Ул – абыең, син – сеңлесе аның...

Салма берүк җанга яраны.
Эшләп йөрде Сәлим җәй буена
Тракторчы егет янында.
Көзен белем ягын каерды ул,
Укырга дип китте тагын да.
Хәрби училище. Ачлы-туклы
Солдат тормышына өйрәнә.
Сагыну сәламнәре килеп тора
Картыйсының моңсу өенә.
«Фотодан мин үбәм күзләреңне,
Күңелемдә назлы сүзләрең.
Араларда озын көнле айлар,
Җаным, Сәлим, ничек түзәрмен!»
Дип язды да, хатны иртән салды.
Җавап хаты озак көттерми.
«Сандугачым, Зифам, кара кашым,
Төштә иренеңнән үптем, – ди, –
Атна буе хатың килми торды,
Түземсезлек белән көттем», – ди.
Зифа быел укый җиденчедә,
Гел Сәлимне уйлап сагына.
Керсез яратудан туган хисләр...
Җилләр илтә Сәлим ягына.

Яз да үтте. Сәлим ялга кайтты.
Зифа җиткән, пешкән алмадай.
Сагынулар чиктән ашкан иде,
Кочаклашмый чара калмады.
Сылубикә дә елмаеп тора,
Бүлешкәндәй алар шатлыгын.
Инде Сәлим аны күтәрде дә,
Биттән үбеп алды картыен.
«Егет егетлеген итми калмас,

Сокландыргыч кыз бар янында.
Үсеп җиткәннәрен күтсеннәр», – дип,
Ана эшли, эшли барын да.
Шомырт бакчасында роза да бар.
Хуш ис сибә роза чәчкәсе.
Алар икәү... Юк, юк, кагылмаслар,
Тәңкәләрен җиргә чәчмәсен...
Өстәл аша кулны кулга алып,
Күзләренә төбәп күзләрен,
Утыралар, һаман серләшәләр,
Бүген бетмәс, ахры, сүзләре.
Ай калыкты.
Әй, ул күрә карау.
Үбешсәң дә күрмәс күзләре.
Сүзләр күчте дөнья хәлләренә,
Искә алды Зифа әтисен...
Кисәк дөнья куйган якын кеше
Кичә генә вафат, әйтерсең.
«Сагыну»ны сузып-сузып җырлап,
Урам буйлап үтте гармунчы.
«Мәрьям туганымның сөйгәне ич,
Бик еш җырлап үтә шул җырны».
«Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
Юлларыңа тезәм мин.
Бик сагындым, бәгърем,
Бик сагындым сине,
Әле дә ничек түзәм мин».
– Бер мәктәптә укыталар иде,
Мәрьям апам белән бу егет.
Сугыштан ул аксак булып кайтты,
Һаман өйләнмәде. Гел боек.
– Бәхетсезлек килде безнең чорга,
Язмышлар авыр шул, кадерлем.

Кар эрегәч, мин дә барып күрдем
Әткәй белән әнкәй каберен, –
Диде Сәлим. Аннан тынлык торды, –
Мәрьям әнкәй ята еракта.
Киләсе ял җәйге каникулда
Икәүләп барырбыз шул якка.

Көннәр үтте.Өр-яңа көз җитте.
Гомер юлкайлары чатлыклы...
Вәгъдәләште алар ташлашмаска,
Ана да бүлеште шатлыкны.
Зифа китте медучилищега,
Ак халатлы кеше булырга.
Ак күңеле белән кешеләргә
Гел ярдәмче булып торырга.
Күңелендә фәннәр һәм мәхәббәт,
Бүлешәләр кызның йөрәген,
Көне буе дәрес – яңа дөнья;
Кич булдымы, уйлый сөйгәнен.
Сәлименнән бик еш килә хатлар -
Мәхәббәтнең утлы күмере...
Ял көнендә җавап яза бара,
Хисләренә төреп күңелен.

Гомер бит ул йөгерек чишмә кебек...
Медсестра кайтты авылга.
Таныклыгы кулда. Зифа монда
Тели иде эштә калырга.
«Җырчы Зифа» диләр иде аны,
Балачактан җырлап үсте ул.
Калын кара чәчле, кара күзле,
Гүзәл артисткалар төсле ул.
Кемнең генә аңа күзе төшми...

Сылу сынын күреп гашыйклар.
Бәлки шуңа... Зифа бу арада
Сәхнәгә чыгарга ашыкмый.
Сәгатьләрне санап көткән кеше –
Сәлим кайтып җитте янына.
Яңгыратып бер җырлыйсы килде:
«Ярым кайтты!» – диеп барына.
Бер атнадан кунак җыйды ана.
Никах мәҗлесендә туганнар...
– Сылубикәкәем» – диләр алар, –
Улың, кызың тиң пар булганнар.
Берсе өчен берсе туганнар.
Бәхетле булсыннар туганнар!
«Гөлсем апаң куна чакырды», – дип,
Мәҗлес үткәч, китте кунакка.
Ә күңелдән уйлый Сылубикә:
«Кушылсыннар, – диеп, – аулакта»,
– Алкаларың, Зифам, алтын түгел,
Сының коелгандыр алтыннан.
Сине бүген алам кочагыма.
Эремәмме синең ялкыннан!
– Бөркетем син минем, Сәлим бәгърем,
Канатың нык, аны беләм мин.
Кыя тауда оя корырбыз, дип,
Канат асларыңа керәм мин.
Шаян сүзләреннән көлештеләр,
Инде кочаклашу, үбешү.
Икәү бер түшәктә беренче төн...
Төннең һәр минуты – сөешү.

Ике көннән өйдә уйлар, уйлар...
Бер минут та онытылу юк.
Уйларның бит була шундыйлары,

Сине ташлап тора белү юк.
Сәлим кайткан икән күчәргә дип,
Өч бүлмәле фатир биргәннәр.
Яшь офицер, фронтовик улы
Бик бәхетле булсын дигәннәр.
Зифа кабул итә бу тәкъдимне:
«Аннан башка ничек яшәргә!»
Сылубикә һич риза түгел,
Мөмкин түгел сорап дәшәргә.
– Ризамын, балакайлар, сезгә,
Кайда әйбәт, шунда яшәгез.
Китә алмам нигеземнән. Юк, юк!
Бу турыда сорап дәшмәгез.
Бик борчыла Сәлим. Газаплана,
Керфек какмый чыга төннәрен.
Ике тормыш... ике якка тарта.
Киңәш сорап, барсын кемнәргә?..
«Бер атнадан кайтып җитәрмен», – дип,
Чыгып китте Сәлим авылдан.
Эшен ташлап, зур фатирын ташлап,
Очып кайтты кабат авылга.
Сылубикә әнкәсен кочаклап,
Иңсәсенә башын салды да:
«Сине ташлап, беркая китмим», – ди,
Әнкәсе йортында калды ул.
Туңга сөрү чоры. Сәлим тагын
Тракторга менеп утырды...
Авылдагы барлык кешеләрнең
Күңеленә шатлык тутырды.

Ничә кабат сайрар кошлар килде.
Ничә кабат күчеп киттеләр.
Еллар инде Сәлимне – инженер,

Ә Зифаны врач иттеләр.
Зур шәһәрдә яши Сылубикә.
Тик олгайды инде, олгайды...
Бик иркәләп, сөеп үстерде ул,
Ике онык – ике малайны.
Ә Мәрьямне...
Инде ничә еллар...
Йөрәгендә яши.
Китмәде.
Күз яшьләре...
Канлы күз яшьләре...
Ничә еллар буе кипмәде.

## ГАЛИМ БЕЛӘН ТАТЬЯНА
(поэма)

Рус белән тормыш
кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә
әхлак алмашып.

Айбүләкнең сабан туе.
Кемнәр генә юк...
Карт-корылар, сылу кызлар,
Яшь егетләр күп.
Кошлар кебек, сайрап тора
Гармун телләре,
Җырчылары бушаталар
Күңел моңнарын.
Атлар чаба. Ат өстендә
Таныш егетләр.
Оча атлар... Егетләре
Яшен кебекләр.
Киң болынның уртасында
Бик зур түгәрәк.
Кемнәр карый баскан килеш,
Кемнәр чүгәләп.
Ә уртада тирә-яктан
Килгән батырлар.
Көч сынаша. Батырларны
Күзли матурлар.
Айбүләкнең үз батыры
Чыкты уртага –
Киң күкрәкле, кара кашлы,
Буйга уртача.
«Эх» дигәнче, Галим бәрде

Бер көрәшчене,
Сузып салды икенчене
Һәм... өченчене.
О, – ди халык, – бу кадәр көч
Кайлардан килә?!
Сөеклесе мондалыгын
Кем генә белә!
Сөйгән яры килгән аның –
Торган сүзендә.
Күтәрергә әзер Галим
Җирнең үзен дә.
Сизелмичә каламы соң
Сөю хисләре!
Шәригать кешеләренең
Китте төсләре.

Кичке уен, кичке бәйрәм
Елга буенда.
Ә гашыйклар сыенганнар
Таллар куенына.
Сандугачлар урын бирә
Кунган куактан,
Сабан туйда ишек ачык
Килгән кунакка.
Төн карасы инде җирдә
Куера бара...
– Тәнзиләм!! – ди, Галим кызны
Куенга ала.
Ефәк кебек йомшак, сары
Толымын үбә.
Диңгез кебек зәңгәр күзнең
Йөзә күлендә.
– Сорап бардым – бирмәделәр,

Имеш, мин – татар...
Сөям, җаным, газаплама,
Гомерлеккә кал?
– Калам, иркәм, синдә калам,
Галим бәгырем...
Гомер итик еракларга
Китеп, кадерлем.
Бала чактан күзем төшкән
Лачыным минем..
– Яшьлек бакчамда кадерле
Кошчыгым минем.

Икәү булып керде Галим
Бүген ишектән.
Ана киленнең киләсен
Иртән ишеткән.
– Байгуҗадан Никитаның
Танясы бит бу!
Әйдә, ярар... ярый, балам,
Өйдәгечә бул.
– Дус кызлары Тәнзилә, ди,
Без дә шулай дик,
Сөйләшкәндә дә торасың
Татар бугай, дип.
Ана күңеле дәрья ул,
Бары да сыя.
Бәхет тели килененә,
Башыннан сөя.
Кемгә очып, кемгә посып,
Җитеште хәбәр.
Кемнәрнедер кайгы басты
Каф тавы кадәр.
Динчеләрнең мыеклары

Тәмам чуалды.
Көфер килгән, динне бозган,
Тынгы югалды.
– Аңла, Галим, – диде мулла, –
Кушмый шәригать.
Ку марҗаңны, я, Ходаем,
Булабыз һәлак.
– Шәригатең бәрсә, бәрер
Башымны ташка.
Яши алмыйм мин дөньяда
Марҗамнан башка.

Рус побы дилбегәне
Тотты бик кыска.
Хрестиан булды Галим
Алдагы кышка.
Березовкада чукынып,
Күтәреп тәре,
Гаврила булып кайта
Татьяна ире.
Чишмәгә суга дип килсә,
Сылу яшь килен.
Балчык салалар чиләккә
Балалар килеп.
«Марҗа, марҗа, марапан,
Марҗа кигән сарапан.
Кара йөрәк, кара кан,
Безнең ашка таракан», –
Дип куалар өйгә кадәр,
Ул көчкә кайта...
Гавриласын күрү белән
Ул чәчкә ата.
Өченче кешене көтә

Ике яшь күңел.
Мәхәббәт үсә, үрелә,
Шиңәрлек түгел.
Авыл кайный, марҗа һаман
Телдән төшмәде.
Динчеләрдә хәйлә... мәкер...
Яшьләр дәшмәде.
Ел үтүгә килеп җитте
Чын кайгы үзе.
Кара күмер кебек көйде
Халыкның йөзе.
Мунча яна ишек алда,
Галим дә чыга.
Ишек артта көткән кендек
Сугып та ега.
Ауды Галим, ауды җиргә,
Ауды мәңгегә.
Иде башын, иде батыр,
Иде тәңрегә.
Ана чыкса, кала катып,
Әйтми киленгә.
Тик секундлар гына калган
Бала килергә.
Алла биргән зур кайгыны
Иңсәгә асып,
Газизенең баш очында
Торганда басып,
Галим кызын кулга ала
Кендекәй әби.
Бисмилласы авызында,
Кулында – бәби.

Байгуҗада яшәгән шул
Бер семья рус.

Авылдагы татарларның
Бары да аңа дус.
Татьянаны алып кайтып
Юатыштылар.
Никитаның зур кайгысын
Уртаклаштылар.
Ә Таняның күп төннәре
Йокысыз үтте.
Терелми ана баладан,
Өзлегеп китте.
Кызчыгының кара күзе –
Галим күзләре.
Таня карый да, саташа,
Чалыш сүзләре...
Ятим калган мәхәббәтне
Сирәкләр аңлый.
Ять-яшь күңел бу кайгыны
Күтәрә алмый.
Калдырырга, дип, кайгысын
Бүәгә килә.
Калын кашларын җыерып,
Дулкыннар көлә.
Кара шәлен ябынган да
Кайгылы башка,
Яр башында тора уйчан,
Караган аска.
Бүә таллары кайгыдан
Башларын игән.
Кояш күмелгән күк йөзе
Карадан кигән.
Таня өчен, ахры, кояш
Мәңгегә сүнде.
Дөньяның бар матурлыгы

Үлде, күмелде.
Жиңде сагыш, күңеленнән
Курку качты,
Бүә суы дулкыннары
Кочагын ачты.
Җилләр исте, моңсуланып,
Ярның башыннан.
Дулкын алды кара шәлне
Таня башыннан.

Җаннары якын булса да.
Диннәре ерак.
Тәннәрен дә якын түгел,
Күмделәр ерак.
Галим белән Татьянадан
Котылды заман...
Халык күңелендә алар
Бергәләр һаман.
Сылу баткан су Бүәдән
Бик күптән киткән.
Ул дулкыннар заман белән
Бергәләп үткән...

## ЭЧТӘЛӘК

Җырым булды юлдаш озын юлда...» ........ 3
Йөрәк, йөрәк ........ 8
Икмәк ........ 9
Җыры калды күңелдә (баллада) ........ 10
Чыршыкаем ........ 12
Тормышны мин гел үземчә аңлыйм ........ 13
Гомерлек ярату ........ 14
Дөнья һаман елый ........ 20
Узган чакта ........ 21
Йөрәгемдә учак ктым мин ........ 22
Күңелләрнең алтын кояшы ........ 23
Кавказ ........ 24
Сугыш калды минем йөрәктә ........ 25
Иркәлиләр нурлар дөньяны ........ 26
Тормыш моңы ........ 27
Эзләнә күңел ........ 31
Өмет бит ул үтми ........ 32
Дуслык ........ 33
Яңгырый җыр ........ 35
Сарай салдым ........ 36
Тузды юләр яшьлегем ........ 37
Тавыш бирәм ........ 38
Онытмагыз ул көннәрне ........ 39
Күңелдә чын сөю булганда ........ 41
Яңа юлдан барам ........ 41
Мин бер дә үзгәрмим ........ 42
Онытылмасын ........ 43
Ирек сөйгән җилләрне көтәм ........ 45
Көт, диләр ........ 46
Алтын алкалар ........ 47
Көзге гөлләр яңа яфрак яра ........ 48
Базар ........ 49
Аклык бизәде ........ 50
Үтте гомер ........ 51
Үземнеке барысы да ........ 52
Моңлы иде язлар ........ 53
Күңелемә юл ябык ........ 54
Яфраклар ........ 55
Көт солдатны ........ 56

Көмеш Ай көлә ........ 57
Имән ........ 58
Җырлыйсым бар ........ 59
Ак бәхетләр китер ........ 60
Йортымны туздырып куймасын ........ 61
Ни булды соң ........ 62
Саумы, Кояш ........ 63
Минем тәрәзәмне кагарсың ........ 64
Нафталанда ........ 65
Солдат йорты ........ 66
Синең алда заман сынаулары ........ 67
Нажар Нәҗми имәне ........ 68
Ялгыз йолдыз ........ 69
Бәхет кибәннәре юлыңа........ 70
Елмаюы – дөнья яме ........ 71
Күңелемнән мәңге китмәссең ........ 72
Йөрәгемдә калды эзләре ........ 73
Яңа язда ........ 74
Узыша яшьлек ........ 75
Чәчкә салам Сезнең кабергә ........ 76
Сагынам ........ 77
Көзнең көмеш көннәрендә ........ 77
Бураннар үткән саен ........ 78
Сиңа ........ 79
Алла кайтты ........ 80
Илле яшьлек егеткә ........ 81
Капка төптә генә калыйммы ........ 82
Акыл китәр безгә, Яңа ел ........ 83
Сөю түрә хәзер күңелдә ........ 84
Төшә кар бөртекләре ........ 85
Күңел кошым ........ 86
Саманта күпере ........ 87
Явызлык бар ........ 87
Комсомол – көч ........ 88
Язылмаган законнар күп ........ 89
Кайтам әле ........ 90
Абыстай ........ 91
Күңел кылым сынды ........ 92
Аклык бизәде ........ 92
Ярату нибирәм таратып ........ 93
Эзли күңел ........ 94

Нигә өздем ........ 95
Теләми бозыклык ........ 96
Син авырсаң, мин үләм ........ 97
Нигә соң ........ 97
Вәгъдә, иркәм ........ 98
Бар байлыгым – күңелем ........ 99
Ана теләге ........ 100
Татар теле ........ 101
Сөю хисе ........ 102
Аю бабай әрләмәсме ........ 102
Болыт үтә ........ 103
Улкыннар ........ 104
Кышкы салкын ........ 105
Кеше файдасына иссеннәр ........ 106
Сау бул, әнкәй ........ 107
Тынычлык өчен ........ 107
Чиккән кебек ........ 108
Сау-сәламәт бул ........ 108
Җилләр булып исәм кайчакта ........ 109
Еладым ........ 110
Урал тауга күтәрелә бер ир-егет ........ 111
Мәңгелеккә таба үтте ........ 112
Еллар юлы ........ 113
Синсез яшәү ........ 114
Машук ........ 114
Космос кызына ........ 115
Яңавылым ........ 116
Дошман болытлар ........ 117
Узган чакта ........ 117
Землянкабыз калыр ........ 118
Фашист ........ 119
Сулган гөлләр ........ 120
Дөньядан яшереп сөйгән яр ........ 120
Йөрәгемдә калды эзләре ........ 121
Җилләр булып исәм кайчакта ........ 122
Ландышлар ........ 123
Оныгым ........ 124
Укытучы булган укучыма ........ 125
Илле биш ел үтте ........ 126
Коллар юк бездә ........ 127
Бурычлымын ........ 128

Кайту ........ 129
Борылганда ........ 130
Күңелдә чын сөю булганда ........ 131
Күңелдә чын сөю булганда ........ 132
Дәрес минутлары ........ 133
Әйт, җаным ........ 134
Аздыр ич ........ 135
Күрә белми дөньяның ямен ........ 136
Моржалар ........ 137
Өр-яңа юл ярып кил, Яңа ел ........ 138
Җилләр җыры ........ 139
Сайрый торган кошлар кайтыр ........ 140
Бәхет китер безгә, Яңа ел ........ 141
Егет егетлеген итә ........ 147
Галим белән Татьяна ........ 165

**Аклима Шариговна САЯПОВА**

**ГОЛОС СЕРДЦА**

Стихи и поэмы

*В авторской редакции*

*Лицензия № 0209 от 06.10.97*

Сдано в набор 29.02.2008. Подписано к печати 04.03.2008.
Формат 60x84 1/16. Бумага офсетная.
Гарнитура «SL_Arial». Печать ризографическая.
Усл. печ. л. 11. Тираж 100 экз. Заказ К-43.

Министерство образования и науки РТ
Редакционно-издательский центр «Школа».
420111, Казань, Дзержинского, 3. Тел.: 292-24-76
Отпечатано на множительном участке центра.



Саялова Аклима Шариговна (1923-2003) – участник Великой Отечественной войны, учитель татарского языка и литературы, автор книги «Вечная мелодия» (Стихи на татарском языке. – Уфа: Китап, 1997), соавтор книг «Акчарлак – 2001» (Альманах на татарском языке. – Уфа: Китап, 2001), «Эхо минувшей войны» (на башкирском и татарском языках. – Уфа: Китап, 2005).